ХЕЗМӘТ БАЗАРЫ

Илдә нинди белгечләргә кытлык бар?

> 15

ГРИПП КИЛӘ!

Белгечләр алдан хәстәрен күрергә өнди

> 16

ИЛДАР ЯГЪФӘРОВ:

«Хәзер шундый вакыт: бөтен фильмнарны да кинозалларга чыгарырга мөмкинлек бар»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 178 (28951) | Җомга | 2 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4 604609 000131



УТТАН АЛЫП, СУГА САЛМА...

1 ДЕКАБРЬДӘН КОММУНАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘРГӘ БӘЯЛӘР АРТТЫ

Кыйммәтләнде! Моны барыннан да бигрәк Чаллы, Түбән Кама, Азнакай, Зәй кебек шәһәрләрдә яшәүчеләр тоячак. Анда коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 12 процентка кадәр күтәрелде. Республика районнарының күбесендә әлеге күрсәткеч 9 проценттан артмый. Аның каравы киләсе 1,5 елда ТКХ бәяләре үзгәрмәскә тиеш. Гыйнварда киләчәк түләү кәгазьләрендә нинди суммалар көтәргә? Газ, ут һәм су өчен кемнәргә ташламалар тиеш? «ВТ» әнә шул сорауларга ачыклык кертергә тырышты.

> 5

Ишетми калмагыз

Мәскәү белән Казанны тоташтырачак түләүле М12 юлында быелга асфальт салу планы үтәлгән. Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин әйтүенчә, юлның 570 чакрымы, ягъни 70 проценттан артыграк өлеше дигән сүз бу. Юл түшәмәсенә барлыгы 5,8 миллион тоннадан артыграк асфальт-бетон тотылган. 48 чакрым озынлыктагы өлешендә автомобильләр йөри дә икән инде. Киләсе елда трасса төзелеп бетәргә тиеш. Татарстанда ул Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Лаеш һәм Питрәч районнары аша уза.

Татарстан ВИЧ-инфекция уртача дәрәҗәдә таралган төбәкләр исәбенә керә. Роспотребнадзор идарәсе белгече Луиза Борисова әйтүенчә, 10 айда чир таралу күрсәткече 100 мең кешегә 167 очрак булган. Россия буенча уртача күрсәткечтән ике тапкыр кимрәк бу. 1 ноябрьгә республикада 15 меңгә якын кеше ВИЧ буенча исәптә тора.

Декабрь аенда кайбер төбәкләрдә, шул исәптән Татарстанда һава температурасы нормадан түбәнрәк булачак. Карның бик аз һәм сирәк явуы көтелә. Россия Гидрометеорология үзәге җитәкчесе Роман Вильфанд сөйләп үткәнчә, Үзәк һәм Идел буе федераль округларында нормадан тайпылыш күзәтеләчәк.
Республикада ял көннәрендә суыта. Шимбә – 3 декабрьдә көндез –12...–17 градус булса, төнлә термометрның терекөмеш баганасы –16...–21, урыны белән –27 градуска кадәр төшәчәк. Якшәмбе – 4 декабрьдә көндез –12...–17, төнлә –19...–24 градус. Явым-төшем юк диярлек. Башлангыч фаразларга караганда, киләсе атна башы – 5–6 декабрьдә көнчыгыш районнарда аз гына кар явып узачак. Көндез –8...–13, төнлә –13...–18 градус булыр дип көтелә.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән языла була!

П2435 жомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен — гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 980 сум 10 тиен — гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

Районнарда ни хәлләр?

Мөслим

25–26 ноябрь көннәрендә Мөслимдә II Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивале үтте. Быел фестиваль бөтен Россиядән килгән катнашучыларны икенче тапкыр җыйды. «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова белдергәнчә, быел бәйгегә Россиянең 37 төбәгеннән, Татарстанның 22 районыннан 400гә якын гариза килгән. Бу – узган ел белән чагыштырганда ике мәртәбә күбрәк, дигән сүз. Район башлыгы Альберт Хуҗин барлык кунакларга рәхмәт белдерде, теләкләрен җиткерде. «Без бүген горурлык хисләре кичерәбез. Үзебезгә дә канат үсүен тоябыз. Безнең шәхси хуҗалыкларда быел гына да бүген 30 меңләп каз үстерелә. Акчага күчергәндә, бу – 60 миллион сум, дигән сүз», – диде ул.
(«Мөслим-информ»)

Зәй

10 декабрьдә «Энергетик» мәдәният сарае каршындагы үзәк мәйданда махсус хәрби операциядә катнашучы ир-егетләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм йөзеннән, авыл хуҗалыгы ярминкәсе уздырылачак. Сатуда җирле җитештерүчеләр ит, балык продукциясе, яшелчәләр, бал һәм башка товарлар тәкъдим итәчәк. Авыл хуҗалыгы ярминкәсендә катнашучы шәхси эшмәкәрләр, крестьян-фермер хуҗалыклары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар һәм үзмәшгульләр сатылган продукциядән керемнең биш процентын хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм өчен бирәчәк. Шулай ук мәйданда гуманитар ярдәм җыю пункты да оештырылачак.
(«Зәй офыклары»)

Теләче

Быел җәй айларында районда «Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалы «Алмаш» сериалын төшерде. Вакыйгаларның күпчелек өлеше Алан авыл җирлегендә барды. Сериалда танылган артистлар гына түгел, райондашларыбыз да катнашты. Һәм менә зарыгып көткән көн килеп җитте – район мәдәният йортында Теләче халкы фильмның беренче ике сериясен карады. Геройлар бик оста итеп уйнап, үзләре дөньясына алып кереп тә китте. Үзебезнең тормышның эченнән алынган вакыйгалар уйландырды. Кадрларда үзебезнең райондашларны күрү исә сериалны безгә тагын да якынайтты», – диде ул.
(«Теләче-информ»)

Әлмәт

Әлмәттәге физик культура көллиятенең беренче курс студенты Владимир Романовны Федерация Советының «Күрсәткән батырлык өчен» медале белән бүләкләделәр. 2021 елның җәендә өч дус – Дарья, Максим һәм Владимир Нократ елгасында биш баланы суга батудан коткарган. «Дусларым белән балаларның кычкырган тавышын ишеттек һәм, эшнең нидә икәнен белгәч, ярдәмгә ашыктык», – дип сөйләде Владимир. Әлеге батырлыклары өчен аларны тантаналы шартларда Россия Федерация Советы рәисенең беренче урынбасары Андрей Турчак медаль белән бүләкләде. Шушы бүләкне алганнан соң, Владимирны көллияттә дә котладылар. Ул үзен герой дип санамый.
(«Әлмәт таңнары»)

БЕЗНЕҢ КЕШЕЛӘР

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ ДЕПУТАТЛАРНЫ РЕСПУБЛИКАГА АКЧА ҖӘЛЕП ИТӘРГӘ ЧАКЫРДЫ

Төп бурыч – үсеш темпын югалтмау. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия сенаторлары, республикадан Дәүләт Думасына сайланган депутатлар белән очрашуда шулай дип белдерде. Утырышта хисапка да, максатка да урын булды.

– Быел безнең ил җитди каршылыклар белән очрашты, әмма җәмгыять үзенең лидеры тирәсендә берләште, – диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов. Киңәшмәдә ул узып баручы елга йомгак ясады.

Санлы мәгълүматлар болайрак: 2022 ел нәтиҗәләре буенча республиканың төбәк тулай продукты 3,8 трлн сумны тәшкил итәчәк, төп капиталга инвестицияләр – 774 млрд, сәнәгать җитештерүендә – 4,8 трлн, авыл хуҗалыгы тармагында – 288 млрд, төзелештә 513 млрд сум булачак.

Сүз уңаеннан, Татарстан Россиянең 27 дәүләт программасында катнаша. Моннан тыш, республика территориясендә 13 илкүләм проект кысасында 49 төбәк проекты тормышка ашырыла. Бу максатларга 40,1 млрд сум күләмдә акча бүленеп бирелгән.

– Безнең бурыч – социаль-икътисади үсеш темпларын саклап калу, – дип басым ясап әйтте Президент. – Хәзерге шартларда республика икътисадына федераль матди ярдәмне мөмкинлек булган кадәр җәлеп итәргә кирәк. Татарстанда инде хәзердән үк федераль финанслау таләп итә торган зур проектлар гамәлгә ашырыла.

Очрашуда Рөстәм Миңнеханов депутат һәм сенаторларга башкарган эшләре өчен рәхмәтен җиткерде. Моннан тыш, ул аларны предприятиеләр белән эшләүгә күбрәк игътибар бирергә, федераль дәрәҗәдә проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә, дәүләт ярдәме мәсьәләләрендә терәк-таяныч булырга өндәде. Шәхси инвестицион проектларны да күздән ычкындырмаска кирәклеген әйтте.

Рөстәм Миңнеханов депутатлар корпусының гуманитар ярдәм юнәлешендә башкарган эшенә тукталды. Республикадан 2 мең тоннадан артык гуманитар ярдәм тапшырылган. Шуларның 660 тоннасы – «Бердәм Россия» партиясеннән.

Депутатлар белән очрашулар традициягә әйләнеп бара. Республикада 17 эш төркеме эшли, аларның һәрберсен депутат җитәкли. Эш төркемнәре составына шулай ук республика министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре дә керә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов йөкләмәсе буенча, эш төркемнәре эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итү һәм координациясен Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин башкара.
Алар түбәндәге юнәлешләр буенча эшли: илкүләм проектларда һәм дәүләт программаларында катнашып, Татарстан икътисадына федераль акча җәлеп итү, республиканың закон чыгару инициативаларын тәкъдим итү, халык гозерләренә җавап табу.

ӘШКӘ БИРСӘҢ ХӘЛӘЛ АКЧА...

Акча хәләл буламы? Бу сорауга җавап биргәндә, икеләнеп торасы да юк. Башкалада ислам кануннарына нигезләнеп эшләячәк банк бүлекчәсе ачылды. Бу – Татарстан гына түгел, ил күләмендә зур яңалык. Ачылыш тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Саклык банкының Идарә рәисе урынбасары Станислав Кузнецов катнашты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Россия мөселман илләре белән дустанә мөнәсәбәтне нығытуга зур әһәмият бирә.

– Ислам финанслары системасы сәүдә-икътисади хезмәттәшлекнең перспективалы юнәлеше булып тора. Ул көнбатыш капитал базарларына һәм сәүдә мәйданчыкларына алмаш та була ала, – диде ул.

Өр-яңа банк бүлекчәсе Казанның нәкъ үзәгендә – Ирек мәйданында урнашкан. «Бу – Татарстанда гына түгел, ил күләмендә тәүге үзәк, – диде Саклык банкының идарәче директоры, партнерлык финанслары һәм махсус проектлар үзәге җитәкчесе Бехнам Гурбан-Задә журналистларга. – Биредә барлык хезмәтләр шәригать кануннары нигезендә күрсәтеләчәк. Без ислам финансларын Россия кануннарына туры китереп эшләдек. Бүген 11 төрле хезмәт күрсәтәбез. Әлеге исемлекне тагын да зурайту күздә тотыла. Хәләл банк карталарын рәсмиләштерә башладык инде. Тәүге банк бүлекчәсенең нәкъ менә Татарстанда ачылуы очраклы түгел. Республика ил күләмендә ислам финанслары өлкәсендә әйдәп баручы булып тора».

Россия мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов әйтүенчә, бу – бөтен ил мөселманнары өчен зур бәйрәм.

– Илдә шәригать кануннары нигезендә эшләүче банк бүлекчәсе ачылганны бик күп еллар көттек. Ниһаять, безгә хәләл кредит рәсмиләштерү, процентсыз исәп-хисап счетлары ачу мөмкинлеге барлыкка килде. Хәзер без үз эшчәнлегебезне ислам кушканча алып барачакбыз, – ди ул.

Билгеле булганча, ислам банк системасында кертемнән процент алу төшенчәсе юк. Ә банкка моннан ни файда, диярсез. Оешма, инвестор буларак, акчаны яңа эшкә юнәлтә. Шул рәвешле, банк та, эшмәкәр дә акчаны югалту куркынычына бертигез дәрәҗәдә дучар. Табышны да икегә бүләләр.

Исламча банк бүлекчәсендә журналистларга «Амана», ягъни шәригать кануннарына туры килүче исәп-хисап счеты да ачып күрсәттеләр. Моның өчен паспорт та җитә икән. «Амана» мөселманнарга үз акчаларын банкта саклау өчен кирәк», – дип аңлатты Бехнам Гурбан-Задә.

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Саклык банкының IT белгечләре өчен технологик үзәк ачуда да катнашты. Технохаб Бәшир Рәмиев исемендәге IT паркта урнашкан. Биредә 250 кешегә санлы продуктлар һәм хезмәтләр тудыру өчен шартлар булдырылган. Замана белгечләре өчен эш урынын да үзләренә туры китереп төзегәннәр. Эш бүлмәләреннән тыш, ял итү, җыелышып сөйләшеп утыру урыннары да бар. Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, Татарстан Саклык банкының күп кенә проектлары, шул исәптән «Мәктәп 21», «Сбер Еаптека» өчен тәҗрибә мәйданы булып санала. «Бүген без ачкан технохаб яңа идеяләрне тормышка ашырырга ярдәм итәр, дип ышанам. Хәерле юл!» – диде Рөстәм Миңнеханов.

ИГЪТИБАР КИРӘК

Кичә – «Бердәм Россия» партиясе оештырылган көнне – Дәүләт Советы Рәисе, партиянең төбәк сәяси советы Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин партиянең республика бүлеге политсоветы президиумы утырышын уздырды. Анда проект эшчәнлеге, Луганск Халык Республикасында яшәүчеләргә гуманитар ярдәм күрсәтү, шулай ук оештыру мәсьәләләре каралды.

Фәрит Мөхәммәтшин, политсовет президиумы әгъзаларын, кайбер район бүлекләре секретарьлары – районнар хакимиятләре башлыкларын, «яшьгвардиячеләр»не партиянең «туган көне» белән котлап, 129 мең кешене берләштергән Татарстан бүлегенең Россиядә иң зуры булуын искәртте.

– Бу сан артында бик зур оештыру эше ята, – диде ул. – Партия без үзенең эшләре белән кешеләрнең ышанычын аклый. Һәрвакыт шулай булырга, сайлаучыларның наказлары, кешеләрнең мөрәҗәгатьләре партия бүлекләренең игътибар үзәгендә торырга тиеш. Уртак эш һәм бердәмлек өчен рәхмәт.

Утырышта сәяси совет Секретаре урынбасары, Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова төбәк бүлегенең проект эшчәнлеге турында сөйләп үтте. Хәзерге вакытта партиянең 19 федераль һәм 3 республика проекты гамәлгә ашырыла. Римма Ратникова тәкъдиме белән «Бердәм Россия»нең хатын-кызлар хәрәкәте» һәм «Күпфатирлы йортларда яшәүчеләр» проектлары өчен җаваплы кешеләрне билгеләделәр.

Партиянең төбәк башкарма комитеты җитәкчесе Марат Сәмигуллин Луганск Халык Республикасында яшәүчеләргә гуманитар ярдәм җыеп җибәрү һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаиләләренә ярдәм итү турында сөйләде. Әлеге республикада яшәүчеләргә март аеннан ноябрьгә кадәр якынча 80 миллион сумлык 660 тонна гуманитар ярдәм юлланган. Азат ителгән территорияләр белән азык-төлек, дарулар, кием-салым, электр җиһазларын җибәрү һәм бүлү буенча уртак эш җайга салынган.

Утырышта партиянең Аксубай, Кама Тамагы һәм Чирмешән районнарындагы җирле бүлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләрен билгеләү мәсьәләсе каралды. Моннан тыш, партиянең республика бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләделәр.

Фәрит Мөхәммәтшин, президиум утырышының эшенә йомгак ясап, партия әгъзаларына халыктан килгән мөрәҗәгатьләргә игътибарны арттыру кирәклеген әйтте.

– Шәхси мәсьәләләр буенча халыкны кабул итүгә бик зур игътибар белән әзерләнергә кирәк, – диде ул, утырышта катнашучыларга мөрәҗәгать итеп. – Кешеләр үзләренә ярдәм буласына өметләнеп килә. Бу – төп бурыч һәм көндәлек эшегезнең төп юнәлешләреннән берсе булып торырга тиеш.

Аңлый алганга аңларлык

КАЗАН ЧИРАТТАГЫ ХАЛЫКАРА ФОРУМГА ӘЗЕРЛӘНӘ

Киләсе атна башында Татарстан башкаласында дөньяның төрле илләреннән 1000ләп белгечне көтәләр. Бөтендөнья табигый һәм мәдәни мирасны саклау турында конвенциянең 50 еллыгына багышланган халыкара форумда Россия белән дус һәм бик үк дус булмаган илләрнең кайсылары катнашачак?

Зур чара турында ТАСС мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында сөйләштеләр. Журналистлар белән онлайн очрашуда Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә әлеге мөһим чарага карата үз фикерен белдерде. Аның сүзләренә караганда, бүгенге геосәяси шартларда әлеге форум үз алдына глобаль бурычлар куя.

Аның фикеренчә, әлеге форумда катнашучылар Россиянең дөньяны гуманитар һәлакәт чигенә куйган эшчәнлеккә һәм масштаблы хәвеф-хәтәрләргә каршы торуын яхшы аңлый.

– Мин әлеге форумның дөньяви мәдәни мирасны үстерүгә һәм ихтирамга омтыла торган цивилизацияләр, мәдәниятләр һәм халыклар арасындагы аралашуның дәвамы булуына ышанам, – дип белдерде Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе.

Шул ук вакытта Көнбатыш илләреннән булган белгечләр дә әлеге форумга карата кызыксыну белдерә икән. Бу хакта Россия тышкы эшләр министры киңәшчесе Григорий Орджоникидзе хәбәр итте.

– Форумда катнашырга теләк белдерүчеләр арасында Россия белән дустанә мөнәсәбәттә булмаган илләр – Италия, Франциядән белгечләр дә бар. Гәрчә аларга каршы санкцияләр кертелү ихтималы булса да. Миңа калса, алар иртәме-соңмы бу хәлләрнең тәмамланачагын яхшы аңлый, – дип белдерде Орджоникидзе.

Григорий Орджоникидзе Татарстандагы тагын бер объектны ЮНЕСКО исемлегенә кертүгә кагылышлы мәсьәләгә дә тукталды. Сүз КФУның Энгельгардт исемендәге астрономик обсерваториясе турында бара. Орджоникидзе белдергәнчә, хәзерге вакытта Россия делегациясе Парижда һәйкәлләрне һәм истәлекле урыннарны саклау буенча халыкара берлек (ИКОМОС) вәкилләре белән бу мәсьәлә турында фикер алыша. Аның сүзләреннән аңлашылганча, нәтиҗә киләсе елда гына билгеле булачак.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, әтисе

ЗАРИПОВ Ринат Абдрахман улы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Зарипов Айрат Ринат улының авыр кайгысын уртаклаша. Сезгә сабырлык телибез.

БЕЗ КАПЧЫКТА ЯТМЫЙ

Соңгы елларда коррупциягә бәйле хокук бозу очраклары өчен җавапка тартылучылар саны арткан. Бу хакта журналистларга Татарстан Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе Салават Рәхимов хәбәр итте. Быел республикада дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарында 245 тикшерү уздырып, 240 хокук бозу очрагы ачыкланган. 231 кеше дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

Әгәр берничә ел элек барлык тикшерүләрнең 80 проценты җәзага тарту белән тәмамланган булса, хәзер әлеге күрсәткеч 96 процентны тәшкил итә.

– Икенче яктан караганда, бүгенгә дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары хезмәткәрләре керемнәре турындагы мәгълүматларны тапшырып бетермәде. Ел бетәргә бер ай калуга карамастан, Биектау районында керемнәрне анализлауга бөтенләй тотынмаганнар да әле! Анда керемнәр турында 127 кеше белешмә тапшырган, – диде Салават Рәхимов.

Аутсайдерлар исемлегендә Лаеш, Ютазы һәм Саба районнары да бар. Ел дәвамында алар барысына бергә нибары 31 кешенең керемнәр турындагы белешмәләрен тикшергән. Ә башка районнарда бу саннар 300дән артып китә. Шулай ук Мәдәният министрлыгына, Инвестиция үсеше агентлыгына һәм Татарстанның сатып алулар буенча дәүләт комитетына да керемнәр буенча белешмәләргә анализ ясамаган өчен шелтә эләкте.

Салават Рәхимов дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары җитәкчелегенең дә игътибардан читтә калмавын әйтте. Быел шундый 33 тикшерү уздырылган. Тикшерү нәтиҗәләреннән соң 27 кеше дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

– Белгечләр яки бүлек башлыклары гына җаваплылыкка тартыла, дигән сүз дөреслеккә туры килми, – ди ул. – Җитәкчелек тә читтә калмый. Быел өч кеше, ышанычны югалту аркасында, эштән куылды.

Керемнәре буенча дөрес мәгълүмат бирмәүчеләр арасында күп ведомстволары хезмәткәрләре дә бар. Татарстан Прокуратурасының коррупциягә каршы тору буенча закон үтәлешен контрольдә тоту бүлеге башлыгы вазыйфасын башкаручы Тимур Нуриев әйтүенчә, ел дәвамында меңнән артык шундый хокук бозу очраклары ачыкланган. 614 кеше җаваплылыкка тартылган. Алар арасында ФСИН, Эчке эшләр министрлыгы, Суд приставлары федераль хезмәте, Яшьләр эшләре, Мәгариф һәм фән, Авыл хуҗалыгы министрлыклары вәкилләре дә бар. Аларның 73е дисциплинар җаваплылыкка тартылган. Шуларның 32се – җитәкчеләр, икесе – министр урынбасарлары. Тимур Нуриев соңгы ике кешенең исем-фамилияләрен атамаса да, аларның Авыл хуҗалыгы министрлыгында эшләүләрен әйтте. Берсе ике җир кишәрлеген һәм Мәскәүдәге фатирда өлеше барлыгын күрсәтүне кирәк дип тапмаган. Икенчесе финанс характерындагы бурычлары һәм счетлары барлыгын яшереп калдырган.

Тимур Нуриев республикадагы уртача ришвәт күләмен дә әйтте. Быелга нәтиҗә ясагач, аның 182 мең сум булуы ачыкланган. Бу – узган ел белән чагыштырганда, 100 мең сумга азрак. Гомумән, 10 айда бирелгән ришвәт 101,4 млн сумга җиткән икән. Быел республикада ришвәтчелеккә бәйле 557 җинаять очрагы теркәлгән. Аларның 193е – ришвәт алу, 265е – бирү, ә 99ы арадашчылык итүгә бәйле.

Гомумән алганда, республикада коррупциягә бәйле җинаять очраклары 1 мең тирәсендә тирбәлә. Мондый хокук бозуларны ачыклау буенча Татарстан 4 нче урында тора. Ә менә Мәскәү, Краснодар крае һәм Башкортстанда мондый төр хокук бозулар күбрәк ачыклана икән.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Әйтеп кенә бактым

Сүгенәсе килә

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Оныгым Кәрим минем намаз укыганны тыңларга ярата. Бакыйлыкка күчкән туганнар, дуслар, танышлар рухына багышлап, аларның исемнәрен саный башлагач, бер көнне Кәрим кинәт: «Дәү әти, син нигә сүгенәсең?» – диде.

– Сүгенмим бит, улым.

– Ә нигә «нафига» дидең?

– «Нафига» түгел, «Шәмси кызы Нәфига» дидем. Татарда шундый исем бар, улым. Күбрәк әнисендә булып, рус тәрбиясендә үскән баланы татарчага өйрәтү бик ансат түгел шул. Ана теле – рус теле аның өчен. Шулай да татарчага өйрәтәбез егетне, үзе дә тырыша.

Кайвакыт сүгенәсе дә килеп китә шул, улым. Тора-бара үзең дә өйрәнерсең әле. Хәер, тормыш нинди генә булмасын, бөтенләй сүгенмәгән кешеләр дә бар. Алар бик тәрбияледер инде, культуралы гаиләдә үскәннәрдер. Алай дисәң, мин дә – интеллигентный гаиләдән. Әти-әни укытучылар иде. Әмма бала оядан чыккач, очканда кайчак башканы да күрә шул. Заманы да башкарак хәзер. Гел сүгенәсе килә. Хәзер телевизион тапшыруларда, телесериалларда да «пошел на фиг», «на фига это нужно», «не фига себе» кебек сүзләр ишетергә туры килә. Алар оныгымның колагына да керә. «Дәү әти, алар ни өчен сүгенә?» – ди. Мин: «Фиг» начар сүз түгел, «фиговое дерево» да бар. Американың бер актеры да Фиг Пол исемле», – дип әйтеп карыйм. Әмма оныгым миңа ышанмый. «Все равно это плохое слово», – ди. Аның белән килешкәндәй итәм. Ә менә рус теленең дә, татар теленең дә ярлылана, чүпләнә баруы хак. Телгә «фиг с ним» дип карый башладык кебек. Сөйләм теле жаргонга якыная.

«Жаргон» – мәгълүм булганча, эшчәнлекнең аерым бер төрен башкаручылар, аерым бер социаль төркемнәр сөйләме. Ярый әле жаргонизмнарның барысын да татарчага тәрҗемә итеп булмый. Юкса телебезнең тәмам рәте китәр, тәме бетәр иде. Инде болай да «чувак», «кореш», «братан», «тачка» кебек сүзләрне мулдан кулланабыз. Жаргон хәтта мәктәпләргә дә үтеп керә башлады. Мәсәлән, «училка», «физра», «шпора» (шпаргалка), «контра» (контрольная работа) кебек сүзләр колакны яра. Мәктәп дигәннән, тел язмышы ата-аналар ихтыярына калдырылгач, «зур кеше» итәр өчен балаларны русча укыту башланды. Әле ул гына да түгел, бер көнне «ВТ» кызлары кайсыдыр авылның балалар бакчасында русча тәрбия бирелә башлавы турында әйттеләр. Монысы да ата-аналар ихтыяры белән икән, балаларыбыз кечкенәдән русчага өйрәнсен, татарча акцентлары да булмасын, диләр икән, имеш.

Сүгенер өчен сәбәпләр чыга гына тора бит. Ул ата-аналарга да сүгенәсе килеп китә, ну ярамый. Моннан берничә көн элек Украина Президенты Владимир Зеленскийның Көнчыгыш Украинада тоташ мобилизация игълан итәчәге турында хәбәр чыккан иде. Монысы нәрсәдер инде. Украинаның көнчыгышында, нигездә, руслар яши. Димәк, Зеленский русларны русларга каршы сугыштырмакчы була. Аны «редиска» диясе килми инде. Президент хәтле Президент тарафына мыскыллау сүзләре дә яргыту килешми, әмма кайчак кыланышлары белән ул «шулер»ны хәтерләтә һәм: «Вы че, в натуре?» – дип куясы килә.

Киләчәктә безнең оныкларны ни көтә икән? Бүген гөнаһсыз сабыйлар күңеленә нинди уйлар сеңдерергә тиешбез?

Бер кызык хәл: яшь буынны ата-бабалар, күркәм традицияләр рухында тәрбияләү һәр халыкта бар. Кайбер илләрдә ни өчен «нацизм», «фашизм» дигәннәре ата-бабалар рухы дип кабул ителә, күркәм традиция буларак яшь буынга сеңдерелеп килә икән? Без үсмер чакта «Американы куып җитик һәм узып китик!» дигән шигарьләр белән дөнья тулы иде. АКШка исә күбрәк дошман итеп түгел, ә көндәш итеп карадык. Дәүләт эзлекле рәвештә «янәшә тыныч яшәү сәясәте» алып барды. Тик бер нәрсә дә без теләгәнчә генә барып чыкмый шул. Һәм, Такташ кебек, «Чемберленның сатыйм анасын, тупка тоткан Мәккә каласын!» – дип сүгенеп әйтеп куясы, үзләрен дөнья тоткасы исәпләгәннәргә: «Вы че, в натуре?» – дип тә өстисе килә.

Оныгым Кәрим кайчак: «Дәү әти, а на Украине кто с кем воюет?» – дип сораштыргалый. Әлбәттә, 8 яшьлек малайга бүгенге катлаулы сәясәтне, бу вакыйгаларның тамыры шактый тирәндә икәнен аңлата алмыйм, бик читен чөнки. «Вакытлыча бәхәс ул, туганнар да кайчак талашып куя бит», – дигән булам. Әллә ни аңламаса да: «Понятно!» – дигән була. Ә мин аның күңеленә кешеләрне, туган илне ярату орлыклары салырга тырышам. Бу орлыклар уңдырышлы туфракка төшәр дип өметләнәм. Менә шундый уйлар белән яшәп ятам. Ә күңелдән генә һаман сүгенәсе, дөнья тынычлыгын бетергәннәрне эттән алып эткә саласы килә.

АУМАСЫН АРБА,

ЯКИ БАЙЛЫКНЫҢ КАДЕРЕН НИК БЕЛМИБЕЗ?

Авылда терлек асрап яшәгән һәркемнең арбага йөк төяп караганы бар. Печәнне арбаның бер ягына күп өйсәң, котылгысыз рәвештә авасың. Хәзерге глобаль икътисадта барган чайкалу һәм көтелә торган зур мәтәлчек арбага печән өюне хәтерләтә.

Икътисадны алга җибәрү өчен, бездә нишлиләр әле? Дөрес әйтәсез: инвестиция ясыйлар. Бизнес һәм физик затлар акчаны саклау, ишәйтү максатыннан да аны нинди дә булса бер юнәлешкә тыгарга тырыша. Кайда табыш күбрәк, капитал шул якка таба ага. Монысына да гаҗәпләнергә кирәкми. Менә без авыллар юкка чыга дип лаф орабыз бит әле. Ит-сөт һәм бөртекле ашлык җитештерү әллә ни табышлы түгел, шуңа күрә авылга инвестиция бик аз салына. Бу эш урыннары кытлыгына китерә. Шулай булгач, кешеләр нишләсен, шәһәргә агыла инде. Шәһәрдә исә торак мәсьәләсе кискен тора. Элек-электән шәһәрдә фатиры булган егеткә кияүгә чыгу кыз кеше өчен бәхет һәм мәртәбә булып санала иде. Шәһәрдәге күчемсез милек муллык, абруй билгесенә әверелә, күпчелек шуңа омтыла башлый. Бу омтылыш көчәйгән саен, фатирларның бәясе арта. Шәһәр фатиры яшәү урыны гына булудан туктый һәм капитал саклау һәм үстерү урынына әверелә. Баш өстендә түбәсе булса да, кеше аның белән генә канәгатьләнми инде, тагын берне алырга тырыша. Арендага биреп акча эшлисең, торакның бәясе үсеп тә сине баета. Ун ел элек сатып алган фатирны хәзер күпкә кыйммәтрәккә сата аласың инде. Әйтик, кинәт кенә акча кирәк булса.

Моннан физик затлар һәм төзелеш компанияләре генә түгел, банклар да файдаланып калырга тырыша. Ипотека кредитының ставкасын да үстерәләр, халыкка аны күбрәк итеп өләшергә дә тырышалар. Әйе, өстенлекле кредитлар да була, әмма алар өчен банкка дәүләт акча бирә. Соңгы пунктка да килеп җиттек: хөкүмәт тә төзелеш базарының үсүе өчен җан атып тырыша. Төзелеш тармагын үстерү икътисадның әллә ничә өлкәсен җанландыра бит ул. Төзелеш материаллары җитештерү арта, сантехника күбрәк кирәк була, металл кою җанлана, боларны җитештерү өчен кирәкле җиһазлар күбрәк сатып алына. Болар һәркайсы салым түли. Шул салымнан хөкүмәт бик үк табышлы булмаган тармакларны тери: субсидияләр бирә, ягъни печтек кенә итеп җим ыргыта. Беренче карашка, монда барысы да искитмәле яхшы күренә. Әмма мондый бәйрәм гел дәвам итә алмый. Сизә торгансыздыр: печән арбаның бер ягына гына өелә. Биегрәк менгән саен, ныграк чайкала андый арба һәм авып та төшә. Без кризис дип атаган нәрсә барлыкка килә. Менә шуның состав өлешләрен бераз тикшерик әле.

Аерым бер кыйммәтләргә бәянең чиксез үсүе акчага ышанычны бетерә. Кешеләр, каударланып, барлык эшләгәннәрен шул кыйммәтләргә тыгарга ашкына. Әйтик, бәясе алай кискен күтәрелмәсә дә, кәгазь акчага караганда ышанычлырак дип, алтын сатып алалар. Хәзерге статистика россиялеләрнең гадәттән тыш дәрәҗәдә алтын коелмалар җыярга омтылуларын күрсәтә һәм хөкүмәтнең алтын сәүдәсен туктатырга ниятләве турында имеш-мимешләр дә бар. Күпчелек торак базарына агыла. Кредит алып, биш бәясенә булса да күчемсез милеккә ия булырга тырыша. Бер бездә генә түгел, бар дөньяда шулай. Кытай кризисын, мәсәлән, икътисадның 25 процентын – төзелеш тармагы, хосусый капиталның 70 процентын күчемсез милек алып тору китереп чыгара.

Фатир бәяләренең чамасыз үсүе исә яхшылыкка алып бармый. Кешеләр ипотека кредитын түли алмый башлый, төзелеш компанияләре җитәрлек кадәр йорт төзеп өлгерә алмый (алданган өлешчеләр барлыкка килә). Артык югары күтәрелгән бәяләргә буй җитмәү сәбәпле, кредит алучылар саны киму тәэбина кучә. Йорт төзелеп бетә, аны алучы юк. Кытай күптән шул полосада инде. Россия дә шуңа кереп бара. Быел ипотека кредитлары күләме 4,7 триллион сумга җитәчәк, ди статистика. Бу үткән елгыдан 19 процентка кимрәк. Төзелеп беткән фатирларны сату михнәткә әйләнә дигән сүз бу. Россиядә хәзер 101233 мең кв. м торак төзелә икән. Шуның 34 проценты гына сатылган. Мәскәүдә яңа төзелгән фатирларның – 41, Санкт-Петербургта – 37, Краснодар краенда 25 проценты сатылган. Кире процессның башланып килүе күз алдында: торак, байлык билгесе булудан туктап, банкротлык чыганагына әверелеп ята. Төзелеш компанияләре кредитларын кайтарып бирә алмый, банклар зыянга эшли.

Төзелгән йортларны җылытырга, сакларга кирәк, ә бу – өстәмә чыгымнар дигән сүз. Ул чыгымнардан котылу өчен генә булса да, һич югы, бәясен төшереп, торакны сатарга кирәк. Бәясе төшә башлаган активның абруе шунда ук бетә: кредит алып, аны процентлар белән түләгәнче, акчаны депозитка салып, процентлар алу яхшырак дигән фикер өстенлек итә башлый. Һәм… без «Российская газета»дан: «Застройщики запускают различные акции и скидки, чтобы простимулировать упавший спрос на квартиры. А владельцы вторичного жилья готовы скинуть до 13% за быстрое проведение сделки», – дигән хәбәр укыйбыз. Бәя төшү – күңелле хәбәр, әмма ул – төзелеш материаллары һәм башка кирәк-ярак җитештерүче компанияләр туктап калачак, кешеләр вакытлыча булса да эшсез калачак дигән сүз. Бюджетка да салымнар явудан туктаячак. Икътисадның моторы аның тормозына әйләнеп бара. Бер бездә генә түгел, дөнья илләренең күбесендә шул хәл күзәтелә.

Бары тик бер илдә генә төзелеш бумы, болытлардан узып, галәмгә таба омтылып ята. Ул – Төркия. Антальяда моннан өч ел элек күчемсез милекнең уртача бәясе 32,1 мең доллар торса, бүген ул – 267,8 мең. Калькулятор: «Үсү темпы 8,34 тапкыр артык», – ди. Кот очарлык сан бит бу! Гади төрек кешесе мондый бәягә фатир сатып ала аламы? Юк! Ул хәтта арендалап яшәүдән дә мәхрүм әле, чөнки аренда бәясе ике ел эчендә 395 процентка үскән. Моннан ун еллар тирәсе элек бу юлларның авторы «Антальяда тәрәзәсе диңгезгә карап торган фатирны 20 мең долларга сатабыз» дигән тәкъдимнәр ала иде. Бөтен дөньяга танылган курорт шәһәрендә фатир шундый гына бәядә йөри иде.

Махсус хәрби операция, тарихта күрелмәгән санкцияләр, мобилизация берсе өстенә берсе ятып, безнең генә түгел, төрек тормышын да астын өскә китерде. Россиядән качкан капитал Истанбулда, Антальяда, Дубайда торак базарын күккә чөйде. Ноябрь ахырында антальялеләр чит ил кешеләренә торак сатмау һәм арендага да бирмәү таләбе белән имзалар җыя башлады. Һәм аларның хәлен бик аңлап була. Яшен тизлегендә Россиядән чыгып киткән акча Әрмәнстан, Грузия, Казахстан, Кыргызстанның эчке тулай продуктын ике урынлы сан белән югары күтәрде. Аларда да арзанга торак арендалау мөмкинлеге бетте. Җирле халык өчен бәлагә әйләнде бу хәлләр. Хөкүмәтләр канәгать, билгеле, салым керә, валюта курслары җирле акча файдасына үзгәрә. Төрекләр, мәсәлән, соңгы көннәрдә генә төп ставканы төшерде, ә лира бу хәлне тыныч кабул итте.

Печәнне арбаның бер ягына гына бу кадәр итеп өю ул илләрдә дә мәтәлчек китереп чыгарачак, әлбәттә. Бүген 30 меңлек фатирны 260 мең долларга сатып алучылар киләчәктә аны ярты бәясенә дә озата алмаячак. Капиталның ташкын булып агылуы чиксез була алмый бит. Һәр ерганак та яңгырдан соң кибә, инешләр кире үз ярларына кайта.

Мине исә башка бер нәрсә борчый. Нинди байлыкларга ия булганбыз без! Аларны дөрес итеп файдаланганда, икътисад арбасына тигез итеп өйгәндә, тормышыбызның матди дәрәҗәсе ничек югары булыр иде! Әмма боларның берсе дә юк. Чит илдә бикләнгән зур байлыклар, чит илдәге күчемсез милеккә тыгылып ятучак акча гына бар.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

УТТАН АЛЫП, СУГА САЛМА...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бу айдан ут, газ, җылылык, су, пычрак суларны агызу һәм каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен кыйммәтрәк түли башларга туры киләчәк. 1 декабрьдән ил күләмендә коммуналь хезмәтләргә бәяләр артты. «Очрашу өчен бик күңелле сәбәп түгел, – дип башлады сүзен тарифлар үсүгә багышланган чарада Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев. – Тарифларны арттыруның чираттагысы киләсе елның 1 июлендә генә көтелсә дә (ә бәяләр гадәттә елга бер тапкыр үсә), ил Хөкүмәте карары нигезендә әлеге чара быел 1 декабрьгә күчерелде». Шул рәвешле, бер ел эчендә икенче тапкыр коммуналь хезмәтләргә бәяләр арта.

Ничарадан бичара дигәндәй, моның котылгысыз адым икәнен дә ассызыклады Александр Груничев. Аның сүзләренә караганда, бу халыкка өзлексез хезмәт күрсәтү өчен кирәк. Бүген республикадагы инженер челтәрләренең өчтән бер өлеше тузган. Татарстанда 5 мең 900 чакрым озынлыкта су үткәрү, 1 мең чакрымнан артык озынлыкта җылылык челтәрен алмаштырырга кирәк. Александр Груничев тынычландырырга да ашыкты: коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 2024 елның җәенә кадәр кабат артмаячак. Шулай итеп, ел ярым дәвамында кыйммәтләнмәячәк.

«Аптырап китмәгез!»

Яңача исәпләнгән коммуналь түләү кәгазьләрен киләсе елның гыйнварында алачакбыз. Декабрь өчен исәп-хисап шул айда ясала. Республика күләмендә бәяләр уртача 9 процентка артты. Казанда, мәсәлән, тарифлар күп дигәндә 10 процентка күтәреләчәк. Ут-суга түләүләр артуны баныннан да бигрәк Чаллы, Бөгелмә, Түбән Кама, Иннополис, Азнакай, Арча, Баулы, Яшел Үзән һәм Зәй шәһәрләре халкы тоячак. Аларда бәяләр 12 процентка кадәр үсәргә мөмкин. Бу исемлектә республиканың шәһәр тибындагы ун бистәсе һәм ун авылы да бар. «Биредә халыкка хезмәт күрсәтүне федераль кануннар белән тәңгәлләштерергә кирәк», – дип аңлатты комитет рәисе. Кыскасы, ут янсын, су аксын өчен кубрәк түләргә туры киләчәк.

Татарстан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов, яңа түләү кәгазьләрен алгач, артык аптырап китмәскә дә киңәш итте. «Кышкы чорда болай да күп түлибез. Коммуналь түләү кәгазьләренә җылылык өчен шактый акча өстәлә. Шуны да истән чыгармагыз», – диде ул. Ут, газ һәм каты көнкүреш калдыкларын чыгару өчен түләү бөтен республика өчен бер үк. Ә менә җылылык һәм су белән тәэмин итү, пычрак суны чыгарган өчен түләү кайда яшәүгә карап аерыла. Яңа бәяләргә аерым тукталыйк.

УТ. 1 декабрьдән республикада яшәүчеләр өчен электр энергиясенең бәясе, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алып, бер кВт/сәгатькә 4 сум 68 тиен тәшкил итте. Электр плитәләре яки электр җылыту җайланмалары булган йортларда яшәүчеләр өчен ул бер кВт/сәгатькә – 3 сум 58 тиен, ә авылда яшәүчеләр өчен – 3 сум 28 тиен. Ике тарифлы исәпләгечләр урнаштырылган очракта, тариф төрлечә булачак, дип аңлаттылар.

ГАЗ ҺӘМ ҖЫЛЫЛЫК. «Зәңгәр ягулык» 53 тиенгә кыйммәтләнгән. Хәзер аның бер куб метры 6 сум 78 тиен тәшкил итә. Бәяләр халык өчен дә, сәнәгать оешмалары өчен дә артты. Монополиягә каршы федераль хезмәт карары нигезендә, 1 декабрьдән илдә газны күпләп сату, аны күчерү хезмәтләре өчен тарифлар 8,5 процентка кыйммәтләнгән. Шуңа күрә халыкка сатыла торган ягулык бәясен дә яңадан исәпләргә туры килгән. «Газ кыйммәтләнгәч, җылылыкка бәя артачагы да көн кебек ачык. Үсеш 7 процент тәшкил итте. Бернишләтеп тә булмый. Җылылык өчен бәя артык күтәрелмәсен өчен, хәлдән килгәннең барын да эшләдек», – диде Александр Груничев.

СУ. Тариф кайсы оешма хезмәт күрсәтүенә карап аерыла.

Мәсәлән, башкала халкы су өчен 2 сум 60 тиенгә кыйммәтрәк түли башлаячак. Аның бер куб метры 27 сум 36 тиенгә җитәчәк. Пычрак суны агызган өчен 6 сумга кубрәк: бер куб метр өчен 33 сум 67 тиен акча чыгарып бирергә туры киләчәк. Әйтик, Чаллыда су – 2 сум 30 тиенгә (бер куб метры – 27 сум 44 тиен), пычрак су агызу – 1 сум 30 тиенгә (бер куб метры – 20 сум 42 тиен) кыйммәтләнәчәк. Түбән Кама халкына суның бер куб метры – 32 сум 10 тиенгә, ә пычрак суны агызуның бер куб метры 21 сум 76 тиенгә төшәчәк. Әлмәттә күрсәткечләр – 47 сум 80 тиен һәм 27 сум 56 тиен.

КАТЫ КӨНКҮРЕШ КАЛДЫКЛАРЫН ЧЫГАРУ. Күпфатирлы йортларда яшәүчеләр өчен әлеге төр түләү 4 сумга артты һәм аена бер кешедән 103 сум 93 тиенгә җитте. Шәхси торак йортларда яшәүчеләргә исә хәзер ай саен җан башыннан 112 сум 74 тиен түләргә туры киләчәк.

Казан халкының коммуналь түләүләргә чыгымнары тагын да артмагае. Билгеле булганча, башкалада яшәүчеләргә кыш көне ишегалдындагы карны чыгарган өчен дә өстәп түли башларга тәкъдим иттеләр. Бәясен дә шактый саллы итеп куймакчылар. Александр Груничев тумаган тайның билен сындырмаска киңәш итте. «Ишегалдындагы карны түгү мәсьәләсе безнең комитетка карамый. Бу эшнең бәясе турында сөйләшергә иртәрәк әле. Иң элек кар тукхан өчен өстәмә түләү кирәкме-юкмы икәнен хәл итәсе бар. Әлеге карар фәкать күпкатлы йортларда яшәүчеләрнең ризалыгы белән генә кабул ителә ала», – диде ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

БӘЯЛӘР ИҢ КҮП АРТКАН ШӘҺӘР ҺӘМ АВЫЛЛАР

9 шәһәр

Азнакай ● Арча ● Баулы ● Бөгелмә ● Зәй ● Яшел Үзән ● Иннополис ● Чаллы ● Түбән Кама

Шәһәр тибындагы 10 бистә	10 авыл җирлеге
Аксубай	Красный Бор
Алексеевск	Яңа Чишмә
Җәлил	Афанас
Карабаш	Кызыл Чишмә
Тенеш	Әбсәләм
Карамалы Тау	Димтамак
Түбән Мактама	Октябрьский
Балык Бистәсе	Осиново
Урыссу	Габишево
Кама Тамагы	Комлы Кавал

БЫЕЛ ГАЗ ҺӘМ УТКА БӘЯЛӘР НИЧЕК КҮТӘРЕЛДЕ?

		1 июль	1 декабрь	арту (%)
Газ (сум/куб.метр)		6,25	6,78	8,5
Ут (сум/кВт/сәгать)	Шәһәр (газ плитәсе)	4,30	4,68	9
	Шәһәр (электр плитәсе)	3,20	3,58	11,9
	Авыл	3,01	3,28	9

КЕМГӘ НӘРСӘ ТИЕШ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бәяләр болай тешләшкәндә, акчаны ничек тә янга калдыру җаен эзләргә кирәк, әлбәттә. Шундый юлларның берсе – коммуналь түләүләргә субсидия рәсмиләштерү, ягъни түләгән акчаның бер өлешен кире кайтару.

– Татарстанда халыкка ярдәм итү максатыннан, ташлама-субсидияләр бирү каралган. Мондый ярдәмгә социаль нормалар һәм нормативларны исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 21 процентыннан артып киткән гаиләләр өмет итә ала. Субсидия рәсмиләштерү өчен, яшәү урыны буенча социаль яклау бүлекчәләренә мөрәҗәгать итәргә яки Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза җибәрергә кирәк. Агымдагы елның 11 аенда 73 мең гаилә матди ярдәм алган. Аларга 956 миллион сум акча түләнгән. 2023 елда әлеге максаттан 2 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк, – диде Александр Груничев.

Субсидия ярты елга билгеләнә, аннары яңадан документлар тапшырырга кирәк. Акчалата ярдәмгә муниципаль яки дәүләт торагында яшәүчеләр, наем килешүе нигезендә фатир алып торучылар, торак кооперативы әгъзалары, фатир, шәхси йорт хуҗалары дәгъва кыла ала. Тагын бер шарт торакның мәйданына бәйле. Ул билгеләнгән стандартларга туры килергә тиеш. Әлеге күрсәткечне һәр төбәк үзе билгели. Татарстанда ул бер кешегә – 40 квадрат метр, ике кешелек гаиләдә җан башына – 23 квадрат метр, өч кешелек гаиләдә исә 17 квадрат метр тәшкил итә. Дәүләттән акчалата ярдәм алганчы, керемнәрне раслап күрсәтергә туры киләчәк. Истә тотыгыз: коммуналь түләүләр буенча бурычлары булганнарга субсидия бирелми.

✓Биш көн яки аннан да күбрәк өйдә булмаган очракта, ут, су һәм газ өчен түләүне яңадан исәпләтергә дә мөмкин. Моның өчен командировкада яки ялда булуыңны дәлилләп күрсәтергә кирәк. Тик шунысы да бар: бу – техник сәбәпләр аркасында өйгә исәпләгечләр куйдырта алмаган кешеләргә генә кагыла.

✓Өч һәм аннан да күбрәк бала (шул исәптән уллыкка алган) тәрбияләүче гаиләләргә дәүләттән ярдәм бар. Аларга коммуналь түләүләргә киткән чыгымнарның өчтән бер өлешен кире кайтаралар.

✓Барлык төркем инвалидларга коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә ташламалар каралган. Наем нигезендә алынган торак өчен (күпфатирлы йорт булганда, аның белән идарә итү, йортның уртак милкен тәзекләндерү, агымдагы ремонт өчен түләү), салкын, кайнар су, ут, җылылык өчен түләгәндә; үзәк җылыту системасы булмаган авыл өйләрендә, җылылык өчен тотылган чыгымнар өчен түләгәндә торак-коммуналь хезмәтләргә 50 процент ташлама бирелә.

✓Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар да коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә аның яртысы кадәр субсидия-ташламадан файдалана. Алга таба махсус хәрби операциядә катнашучылар, өйгә кайтканнан соң, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар исәбенә кертеләчәк һәм ташламалардан файдалана алачак дип тә көтелә. Исән-сау гына булсыннар! «Мобилизациягә китүчеләрнең гаилә әгъзаларына коммуналь түләүләр өчен субсидия-ташлама бирү каралмаган», – дип хәбәр иттеләр Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәтеннән.

«Коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр сизелерлек артты, – диде Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе. – Без халыктан гел ризасызлык сүзләре ишетеп торабыз. Алга таба андыйлар тагын да күбәячәк. Тик төзекләндерү, ремонт эшләре кирәк дип чаң суккан оешма-предприятие җитәкчеләрен дә аңлап була. Шуңа күрә ике арада алтын урталыкны табарга кирәк». Чыгымнарны исәпләп тә күрсәтте ул. Казанда, мәсәлән, дүрт кешелек гаилә кышкы чорда коммуналь хезмәтләр өчен аена уртача 7 мең сум акча түли. Яңа елдан соң гаиләнең әлеге чыгымы якынча 700 сумга артачак. «Моннан да күпкә кыйммәтләнә икән, димәк, тикшерергә кирәк», – диде Александр Груничев. Көтәсе күп калмады...

Зөһрә САДЫЙКОВА

МИЛЛИОНЕР АВЫЛЛАР

Иш янына куш өстәлсә, тагын да күңеллерәк. Авылларга бирелә торган дәүләт ярдәме, грантлар турында халык әнә шулай ди. Аларның әһәмияте ни дәрәҗәдә зур? Ярдәм алуда нинди авырлыклар бар? Без шул хакта белештек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ярдәм күп булмый

Билгеле булганча, тугыз ел дәвамында авыллар һәм административ үзәк булмаган бистәләр, республика конкурсында катнашып, грант алу бәхетенә ирешә. Әлеге акчалар авыллардагы зур эшләрне башкарыр өчен тотыла. Шушы тугыз ел эчендә бәйгедә 43 районнан 2416 җирлек катнашкан. Аларның 1250се зур ярдәм алуга ирешкән. Бәхетлеләрнең 1238е – авыл җирлеге, 12се – административ үзәк булмаган бистә. 2019 елдан авыл җирлекләренә – 1,5 млн сум, бистәләргә 2 млн сум грант бирелә.

– Әлеге грантларда пассивлык күрсәткән районнар юк диярлек, чөнки бу ярдәмнең авыл өчен ни дәрәҗәдә кирәклеген бик яхшы аңлыйлар, – диделәр безгә «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясендә. – Иң яхшыларны исә башкарган эшләре буенча сайлап алалар. Монда җирлекләрнең салым керемнәре, торак төзү, кече эшкуарлар, җинаятьләр саны һәм башкалар исәпкә алына. Ел саен 170 авылга грант бирелә. Бу акчага җирлекләрдә юллар, күперләр төзекләндерелә, суүткәргечләр салына, кар чистарту техникасы сатып алына.

Грант күләме буенча яңалык та бар. Республика җитәкчелеге киләсе елдан авыл җирлекләре өчен грантлар күләмен – 2,5 млн сумга, бистәләр өчен 3 млн сумга кадәр арттыру мәсьәләсен карый. Авыл халкы үзе бу хакта ни уйлый соң? Грантлар авылны саклап калуда ярдәм итәме? Аларның үзләренә сүз бирик.

Өч елга – җиде грант

Кукмара районының Сәрдекбаш авыл җирлеге грантлар алу саны буенча башкаларга үрнәк булып торырлык. 2015 елда шушы ук грантка ия булганнар иде инде алар. Ул вакыттагы 1 млн сум акча җирлеккә кергән җиде авылны светодиодлы лампалар белән тәэмин итәргә җиткән. Быелгы 1,5 млн сумга исә авылга керү юлына асфальт салынган. Җиде авылны берләштерүче җирлектә 1350 кеше яши.

– Мондый ярдәмнәрнең авыл өчен кыйммәте бик зур. Халык та күрә, сөенә, рәхмәтле була белә, – ди җирлек башлыгы Илгиз Нәбиев. – Бу грантны алырга теләүчеләр бик күп. Районда эшеңне күреп, тәкъдим итүләре шулай ук ышаныч уята. Конкурс шартларында аны алу авылның дәрәҗәсен күтәрә, дип саныйм.

Моннан тыш, узган елларда 2 млн сум федераль грантка ия булган авылларның берсе дә – Сәрдекбаш җирлеге.

– Монысы – тулысы белән диярлек район башлыгының тырышлыгы, – ди Илгиз Нәбиев. – Районга ике елда 176 авылга шундый грант алуга иреште. Аны алыр өчен район да, җирлекләр дә үзләреннән күпмедер өлеш кертергә тиеш. Безнең җирлек кенә узган өч елда «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасы буенча 7 грант алды. Шуның нәтиҗәсендә авылларда спорт мәйданчыклары, һәйкәл ясалды, юллар каралды.

Федераль, республика грантлары өлешенә әллә нигә бер тапкыр тисә, үзара салым акчасы исә – ел да килә торган ярдәм. Аның ни дәрәҗәдә мөһимлеген авыллар аңлады инде.

– Узган ел – 5 млн 400 мең сумлык, быел 5 миллионнан күбрәк суммага эшләр башкарылды. Сер түгел, авыл советларының бюджеты үзенә җитәрлек кенә. Грантлар, үзара салым акчалары булмаса, әллә нинди зур эшләр башкарып булмас иде. Монда, билгеле, халыкның да өлеше зур. 3–5әр мең сум җыйган авыллар бар, – ди Илгиз Нәбиев.

Барысы да – күз алдында

Быел грант алучы бәхетлеләр исемлегендә Зәй районының Аксар авылы да бар. Җиде авылны берләштергән җирлектә 1600 кеше яши.

– Суүткәргечләр 1965 елларда колхоз көче белән салынган, димәк, шактый тузган иде. Грант акчасын бер урамда шуларны алыштырыр өчен кулланырга булдык. Әлегә без грантның 386 мең сумын гына файдаландык, калганнарын киләсе елда тәмамлаячакбыз, – ди җирлек башлыгы Юрий Гыйльманов. – Ел саен алып була торган акча булмаса да, 3–4 елга бер тапкыр эләксә дә, зур сөенеч инде. Билгеле, грантлар эш нәтиҗәләре буенча бирелә. Ләкин шул ук вакытта без башка җирлекләр белән дә аңлашып эшлибез. Районда 22 авыл җирлеге бар һәм без бердәм. Бер-беребез белән киңәшләшеп яшибез. Әйтик, минем күршегә ул ярдәм тагын да кирәгрәк икән, сабыр итеп, аңа юл бирәбез.

Моннан тыш, быел авыл «Татнефть» грантын алырга да өметләнә. Үзара салым акчасына да зур эшләр башкарыла. Биш зиратның иксеннең коймаларын алыштырып бетергәннәр, юлларны тәртипкә китергәннәр, һәйкәлләр төзегәннәр.

– Менә шулай үзебез эшләргә тиешле эшләрне акрынлап киметә барабыз. Иң мөһиме – барысы да халыкның күз алдында. Шуңа күрә аңлау да бар. Авыл өчен бик зур ярдәм бу. Ул күбрәк булган саен, тагын да тырышыбрак эшлисе, тагын да күбрәк аласы килә башлый. Ләкин һәрнәрсәнең чамасы бар. Шуңа күрә үзебезгә дә тырышырга туры килә. Бу мәсьәләдә үзара салым бик зур ярдәм. Эше, мәшәкате күп булса да, нәтиҗәсе сөенечле. 2016 елдан бирле өч һәйкәл ачтык без. Халыктан башка булмый, шуңа күрә бер-беребезне аңлап-санлап эшләргә тырышабыз, – ди җирлек башлыгы.

«Күптәннән көттек»

Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегендә 129 хуҗалык бар. Аларда 400дән артык кеше яши. 1,5 млн сум грант акчасын быел су башнясын алыштыру өчен тотканнар.

– Сыйфатлы су халыкны иң нык борчыган мәсьәлә иде. Без моны күптәннән көттек, – ди авыл җирлеге башлыгы Николай Морозов. – Эчә торган су 60 метр тирәнлектән күтәрелә. Шунлыктан аның катылыгы зур, савытларга бик тиз юшкын утыра иде. Әлеге акчага башняның үзен алыштырдык һәм суны 80 метр тирәнлектән алырга телибез. Икенче башняда насос начарайган иде. Аны да алыштырдык.

Моннан тыш, гидрантлар куйганнар, башняның моңа кадәр тимер челтәр белән уратып алган территориясен профнастил белән тотып куйганнар, ун метр чамасындагы катлаулы трассага ком-таш кушылмасын җәйгәннәр.

– Әлеге вазыйфада өч ел эшлим мин. Һәр ел саен катнашып килдем, ә менә җиңү бәхетенә быел гына ирештек. Актив булсак та, бездән дә күбрәк эшләүчеләр бар. Озаграк көтәргә туры килсә дә, үҗәтлек белән ахырга кадәр барырга кирәк. Район хакимиятеннән башка гына булмый. Аларның теләктәшлеге булмаса, берни дә эшләп булмас иде. Бердәмлек булганда гына шундый ярдәм алырга мөмкин, – дип саный Николай Морозов.

Мондый зур эшләр башкарганда, халык фикеренең беренче урында булуын әйтте ул.

– Мин үзем генә берни дә хәл итә алмыйм. Барысы да халык белән киңәшләшеп эшләнелә. Шул вакытта гына нәтиҗә булачак. Быел җирлектә үзара салым акчасына да зур эшләр башкарылды. Керәшен Сәрдәсендә һәм Көлкәмәрдә юл проблемасын тулысынча хәл иттек, дип әйтергә була. Үзара салым буенча быел да җыеннар уздырдык. Бездә җырга-биюгә бик һәвәс халык яши. Кунакларга да, өлкән яшьтәге тамашачыларга да уңайлы шартлар тудырасыбыз килә. Шуңа күрә быел җыелган акчага клуб каршында җәйге мәйданчык ясамакчы булабыз, – дип, планнары белән уртаклашты башлык.

Аның фикеренчә, мондый ярдәм халыкны авылларда саклап калуның бер чарасы булып тора.

> Мин моңа чынлап торып ышанам, – ди ул. – Авылларны юлсызлык бик нык тилмерткән иде. Кечкенә авылларыбызда бернинди дә җитештерү оешмалары, эш урыннары юк. Шуңа күрә халык Питрәчкә, Казанга йөреп эшли. Юллар начар булгач, авылдан чыгып киткәннәр башка кайтмау турында уйлый иде. Хәзер вазгыять башка. Яшьләр авылга кайтып йөри, кемдер йорт тергезде, кемдер әти-әнисе йортында тора. Кайтып-китеп йөрергә елның теләсә кайсы вакытында юл бар. Бу яктан мондый ярдәмнәр бик вакытлы.

Документы катлаулы, әҗере әйбәт

Быел грант отучылар арасында Азнакай районының Югары Стәрле авыл җирлеге дә бар. Башлык Лилия Сабирҗанова әйтүенчә, акчаны мәдәният йортын төзекләндерү өчен тотканнар. Әлеге грантны беренче тапкыр алулары икән. Аңа кадәр юллар буенча программада катнашып, үзәк урамга асфальт салынган.

– Узган ел «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасында катнашып, авылда парк төзедек. Урам утларының бер өлешен үзара салым акчасына, бер өлешен программа нигезендә бирелгән акчага куйдырдык. Чыннан да, бүген авылдагы бөтен зур эшләр грантлар, үзара салым акчалары һәм башка программалар ярдәме белән башкарыла. Юллар, зиратлар, һәйкәлләрне карап тоту, урам утлары, юлларны кардан чистарту, авылга керү өлешендәге стелаларны яңарту – һәммәсендә дә аларның ярдәме зур. Бер генә җирлек тә аларда катнашудан баш тартмый торгандыр, дип уйлыйм. Катнашуын катнашабыз инде, тик соңгы елларда узу гына катлаулырак. Безгә, мәсәлән, 1,5 млн сумлык грантны алу икенче талпынышта гына насыйп булды. Документ җыю җиңел булмаса да, нәтиҗәсен күргәч, күңелле. Дөрес, авылларда инфраструктура булганлыктан гына авылда кеше кала, дип әйтә алмыйм. Ләкин монда яшәүчеләр өчен бу ярдәмнәр бик мөһим.

МЕҢЕ БЕЛӘН КАЙТАРУ

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Алган чакта карчыга, биргән чакта җан чыга» дигән халык мәкале бар. Кредитка атап әйткәннәр, диярсең. Җанны айкаса да, әҗәт упкынына сикерүчеләр саны аз түгел. Соңгы мәгълүматларга караганда, илдә яшәүчеләрнең банкларга булган әҗәте 25 триллион сумнан артып ук киткән. Игътибарны җәлеп итәрлек тагын бер сан: кредитын вакытында түләр өчен кабат әҗәткә керүчеләр саны 55 процентка җиткән. Кредит йөккә әйләнмәсен өчен нишләргә?

Халыкны кредит алуга этәргән сәбәпләр күп төрле. Рәхәт тормыштан мөрәҗәгать итмиләр, билгеле. Алдарак телгә алынган процентлы санга тәэсир итүче сәбәпләр дә бар. Әйтик, ил халкының соңгы еллардагы пандемия, чикләү-санкцияле яшәеше, финанс кыенлыклары, бәяләр үсеше.

Кредит физик һәм юридик затларга гына ярдәм итеп калмый, икътисад өчен дә әһәмиятле корал ул. Реаль керемнәргә генә яшәгән халык белән нинди көчле икътисад көтәргә? Дәүләткә дә актив кулланучылар кирәк бит. Әмма кредит бирү юнәлешендә төп бәла – заемчыларның үз көчләрен дөрес итеп бәяли белмәве һәм күтәреп булмастай бурычларга ризалашуы.

Россиядә кредитын вакытында түләр өчен кабат әҗәткә керүчеләр өлеше 49 процентан 55кә җиткән. Кредиттан котылу өчен, керемнең 10 процентан артыграгын бирәләр. Белгечләр моны инде уйланырга җирлек дип саный. Табышларының 80 процентын әҗәт кайтару өчен тотучылар тагын да сагайта. Бу инде – халыкның финанс өлкәсендә белемсез булуына да ишарә.

ӘҖӘТЛЕ ТӨБӘКЛӘР

№	Төбәк	Хезмәткә яраклы бер кешегә туры килгән бурыч (сум)
1	Ямал-Ненец авт. округы	588681,47
2	Ханты-Манси авт. округы	537425,26
3	Магадан өлкәсе	514109,26
...		
7	Мәскәү өлкәсе	47109,88
...		
10	Мәскәү	447829,06
...		
25	**Татарстан**	**337632,48**
...		
30	Удмуртия	323383,37

«Бробанк» хезмәте мәгълүматлары буенча

Әҗәткә бату – чир

Нәрсә дисәләр дә, соңгы дистә елларда кешенең тормыш-көнкүреше үзгәреш кичерде. Ашау-эчү, кием-салымда төрлелек бар, ял, күңел ачу мөмкинлекләреннән файдаланырга була (нинди күләмдә булуына карамастан). Моңа акча җитмәсә, алдарак язганыбызча, кредит бар ич. Шуның белән бергә кредитка бәйлелек (кредитомания) дигән төшенчә дә барлыкка килде. Психологлар аны компьютер, комарлы уеннарга бәйлелек белән бер рәткә куя. Кредит карталарының пәйда булуы да кешеләрнең аңын үзгәртте: буй җитмәслек нәрсәләргә юлны шушы кечкенә генә катыргы ача икән бит! Кредит алган кеше аны кайтара аласына ихластан ышана. Хәтта аларның саны бик күп булса да. Әмма бәйлелек аяныч нәтиҗәләргә дә китерергә мөмкин шул.

Бәйлелекнең билгеләре дә бар. Кешедә аларның күпчелеге шәйләнә башлаган икән, бу инде – белгечләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк дигән сүз.

Чынбарлыкны дөрес итеп кабул итмәү һәм аңа пассив мөнәсәбәт белдерү – сәбәпләрең берсе. Әйтик, кешенең хезмәт хакы 30 мең сум тирәсе, ә бурычлары миллионнар белән исәпләнә, ди. Ул: «Мин аларны кайтарам, мин барысын да аңлыйм, әмма әлегә берни эшли алмыйм», – кебек акланулар эзли башлый.

Алдашу, якын кешеләрдән әҗәткә акча сорап, аларны кире кайтармау да – сәбәп. Моңа өстәп, кешедә психологик киеренкелек, борчылу һәм ярсу хисләре арта.

Әҗәтләрнең психологиясе җаваплылыктан качуга корылган. Алар бурычлары өчен дә, тормышлары өчен дә үз җилкәсенә җаваплылык йөген алырга теләми.

Акча туплаудан туктау, акчасы булмаган килеш кыйммәтле нәрсәләр сатып алу, кредит картасын соңгы тиененә кадәр куллану – бу да бәйлелек корбаннарының билгеләре.

Психологлар сүзләренчә, кредитоманиядән котылу өчен, иң элек фикерләүне, аңны үзгәртергә кирәк. Үз кенегез өчен җаваплылык – бары тик сезнең генә өстә бит.

«Дисциплина» сүзе белән дуслашырга кирәк булыр. Кредитоманнарның күбесе уйламыйча сатып алулардан тәм таба. Әмма көндәлек тормышта ямь-төм табарлык башка күренешләр дә бик күп. Һәм иң мөһиме: аларның күпчелеге акча сорамый.

Әҗәтленең бурычлары... йөзеннән күренә

25–40 яшьлекләр – иң әҗәтле кешеләр икән. Бөтен бурычлыларның 50 проценты шул яшь категориясенә карый. Профессиональ коллекторлар ассоциациясе (НАПКА) илдә яшәүче кредит корбаннарының портретын тасвирлап караган.

Белгечләр мәгълүматлары буенча, бурычлы кешеләрнең 20 проценты – 41–50 яшьлек кешеләр. 18–24 яшьлекләргә 10 процент туры килә. 51–60 яшьлекләр – 15, 60 яшьтән өлкәнрәкләр 5 процентны тәшкил итә.

– Бурычлының якынча портреты – бурыч күләме уртача 100–150 мең сумны тәшкил иткән, бурычын түләргә 90 көнгә соңарган, гаиләсе булган, урта яки югары белемле, 40 яшьләр тирәсендәге ир-ат яки хатын-кыз, – дип искәртә әлеге хезмәт белгечләре.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Белгеч сүзе

Хәзерге заманда кредит алудан да җайлы нәрсә юктыр. Вәсвәсәгә бирелми кара син! Бер тапкыр алганчы, биш кат уйларга кирәкме? Кредит бурычын киметеп буламы? Банклар да кредитны сораган саен бирәме? Арбитраж идарәчесе ярдәмчесе **Алсу ӘХМӘТОВА**дан шулар турында сораштык.

:: Алсу ханым, халык акчасы белән идарә итә белми. Бу нишләп шулай?

– Бу күренеш тамырлары бик тирәннән килә. Әйтик, мәктәптә финанс белеме бирү юк. Өйдә дә бит балалар әти-әниләренең ничек итеп акча тотуларын күреп үсә. Алар да үз әти-әниләреннән күреп үскән була. Финанс белеме бик сай һәм өйрәнергә теләүчеләр бик аз. Финанс белеме мәктәптә дә бирелсә, акчаны арттыру ысуллары өйрәтелсә, иң гади сорауларга җаваплар табарга булышса, әлбәттә, күпләр бу юнәлештә аңлырак булыр иде.

:: Кредит алу хәзер шулкадәр җиңел, җайлы. Моның да үз уңай һәм тискәре яклары бар бит инде?

– Уңай яклары: кешегә акча бик кирәксә, банкка мөрәҗәгать итеп була. Әйтик, дәвалану, белем алу өчен, дисеңме. Банкка бу акчаны соңрак кайтару шартлы белән мөрәҗәгать итәсең. Кимчелеге исә – бер кредит өстенә икенчесен алу мөмкинлеге. Шуның аркасында, әҗәт упкыны барлыкка килә дә инде.

:: Бәлки, банкларга элеккеге бурычын кайтармаган кешеләргә яңа кредит бирмәскә дигән шарт куяргадыр?

– Хәзерге көндә андый закон юк. Бу инде – банк ихтыярында кала торган мәсьәлә. Банк гаризаны кабул итә икән, җаваплылык аңа да төшә. Алар кредит алучының түләрлек хәлдәме-юкмы икәнен тикшерергә тиеш бит.

:: Бурыч йөген ничек киметергә соң?

– Барыбызга да билгеле ысуллар: реструктуризация, кредит каникулы һәм рефинанслау. Әмма сезнең бурыч күләме бик тә зур булып, әҗәт күләмен капларлык дәрәҗәдә хезмәт хакы алмыйсыз икән, 127 номерлы Федераль закон нигезендә физик затларны банкрот итеп тану процедурасын киңәш итәм. Бу закон – авыр хәлдә калган кешеләргә зур ярдәм, дип саныйм. Түли алмаган очракта, Арбитраж суды аркылы мөрәҗәгать итсәк, кеше шушы кредитлардан азат ителәчәк.

Хокук

Булат ЗАКИРОВ, «Ватаным Татарстан» юристы:

– Беренчедән, матди мөмкинлекләрегезне объектив бәяләгез, хисләр тәэсирендә кредит алмагыз. Аннан, кредит акчасын бирү шартларын һәрвакыт игътибар белән укыгыз, аерым алганда, процент ставкасы, кредитның гомуми күләме, вакытында түләмәгән өчен нинди җаваплылык каралганын истә тотыгыз. Шулай ук килешүгә кул куйганда, менеджерга сораулар бирергә икеләнмәгез, абстракт җаваплар белән генә чикләнмәгез. Үз исемегездән танышларыгыз өчен кредит алмаска киңәш итәм. Ул-бу булса, иң элек проблемалар сездә булачак.

Кредит түләүләре буенча бурыч барлыкка килсә, нишләргә соң? Иң мөһиме – паникага бирелмәскә һәм элегрәк алган кредитны каплар өчен яңасын алмаска. Банк хезмәткәрләреннән дә качарга кирәкми. Киресенчә, алар белән иң беренче элемтәгә чыгыгыз, офисларына барыгыз, кыенлыкларыгызның сәбәпләрен аңлатыгыз. Банк кредит каникулы бирергә, реструктуризация уздырырга, түләү графигын үзгәртергә хокуклы. Сөйләшүләр белән генә мәсьәләне хәл итеп булмаса, алга таба сезне суд процессы көтәчәк. Бу очракта да куркырга кирәкми. Суд утырышларының максаты – кредиторның да, бурычлы кешенең дә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен исәпкә алып, бәхәсне хәл итү. Шуңа да суд хатларын игътибарсыз калдырмас өчен, почтагызны тикшереп торыгыз. Судка чакыру алсагыз, суд утырышларына йөрергә кирәк. Суд бәхәсне сездән башка да карый алачак, ләкин процесста катнашып, үз хокукларыңны яклау күпкә җиңелрәк булачак. Әйтик, штраф санкцияләре күләмен киметеп була. Еш кына «неустойка» төп бурыч суммасыннан артып китә бит. Суд карарын үтәү белән приставлар шөгыльләнә. Башкарма производство барышында сезнең мөлкәтегезгә, банк счетларына һәм башкаларга арест салынырга мөмкин. Истә тотыгыз: 2021 елдан бурычлы кешенең бердәнбер торагын да алырга мөмкиннәр.

5 декабрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар.Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12
09.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК» 16+
13.00 «Семь дней» Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «Бичаракай» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Рыцари вечности». Цветаева 12+
00.05 «Фолиант в столетнем переплете» 12+
00.20 «Таяну ноктасы» 16+
00.00 «Ватандашлар» 12+
01.10 «Кәмит Җәвит» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
18.50 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости с субтитрами
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45, 03.05 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
21.00 «Время»
21.45 Памяти Сергея Пускепалиса. «ШИФР» 16+
22.45 «Большая игра» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Вести. Местное время
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном» Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Вести. Местное время
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.05 Вести. Местное время
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-22» 16+
22.25 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров и Екатерина Кистень в телесериале «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15, 14.50, 17.00 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.45, 14.55, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола». Прямой эфир
12.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Обзор 0+
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «МИНСК» (Белоруссия) – «Пари НН» (Нижний Новгород) 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.35 «ПРИГОВОРЕННЫЙ» (S) 12+
02.05 «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 6 кадров 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведемся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00, 01.05 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча» «Найти и потерять» 16+
13.35, 00.05 «Знахарка» 16+
14.10, 00.35 «Верну любимого» 16+
14.45 «ЧУЖАЯ ДОЧЬ» 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «ОТПУСК В СОСНОВОМ ЛЕСУ» Начало 16+
20.30 «Шаг в карьеру» 16+
20.35 «ОТПУСК В СОСНОВОМ ЛЕСУ» Продолжение 16+
23.00 «Порча» «Пригвожденный» «Овощи» 16+
02.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+

ЗВЕЗДА

06.05 «Оружие Победы. Щит и меч Красной армии. Битва за Москву» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ФРОНТ БЕЗ ФЛАНГОВ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.25, 15.05 «КОМАНДА 8». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Холодная война. Битва экономик» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым» 12+
22.55 «Между тем» 12+
01.10 «В ТРУДНЫЙ ЧАС» 12+
02.50 «ПРЕКРАСНАЯ ЕЛЕНА» 16+
04.20 «Военный врач Николай Пирогов» 16+

6 декабрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар.Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Барыс» – «Ак Барс». Прямая трансляция 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00, 00.15 «Соотечественники» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.45 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
01.10 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05. 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30 «Татар халык җырлары» 6+
16.0, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
18.50 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости с субтитрами
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45, 03.05 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
21.00 «Время»
21.45 Памяти Сергея Пускепалиса. «ШИФР» 16+
22.45 «Большая игра» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Вести. Местное время
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Вести. Местное время
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.05 Вести. Местное время
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-22» 16+
22.25 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров и Екатерина Кистень в телесериале «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15, 14.50, 17.00 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.45, 14.55, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола». Прямой эфир
12.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Обзор 0+
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. 1/8 финала. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Мужчины «Чеховские медведи» (Московская область) – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.20 «Англия – Россия. Коварство без любви» «Битва за третий мир» 16+
01.30 «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+
04.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведемся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00, 01.05 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Дурочка» 16+
13.35, 00.05 «Знахарка» 16+
14.10, 00.35 «Верну любимого» 16+
14.45 «ЧУЖАЯ ДОЧЬ». 5-я – 8-я серии 16+
19.00 «СКАЖИ ТОЛЬКО СЛОВО». Начало 16+
20.30 «Шаг в карьеру» 16+
20.35 «СКАЖИ ТОЛЬКО СЛОВО». Продолжение 16+
23.00 «Порча». «Зов прошлого». «Маленькая принцесса» 16+
02.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+

ЗВЕЗДА

04.55 «ДЖОКЕРЪ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ФРОНТ БЕЗ ФЛАНГОВ» 2-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00, 15.05 «ТОЧКА ВЗРЫВА». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Холодная война. Битва экономик» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» 12+
01.10 «ПОВЕСТЬ О ЧЕКИСТЕ» 12+
02.40 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+
04.00 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 1-я и 2-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Төзелеш өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Евростиль» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гайсин** Илнар Ленар улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җирләү йолаларын оештыру идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Ишкин** Марат Әдһәм улы, республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Туган Як» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сәүбәнов** Фәрхәт Корбангали улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүләре өчен «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Калаганова** Нина Ивановна, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе труппа мөдире – баш режиссеры ярдәмчесе **Лукина** Любовь Николаевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Әкият» татар дәүләт курчак театры дәүләт бюджет учреждениесенең курчак уйнатучы артисты **Дмитриева** Елена Юрьевнага, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Мөхәммәтҗанов** Фәннур Фәнис улына, автор-алып баручы, «Эфир» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең программалар алып баручысы **Иванов** Алексей Ивановичка, вокалчы артист (солист), «И.В.Әухәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең академик җырлау бүлекчәсе укытучысы **Исламова** Эльза Евгеньевнага, Мәскәү шәһәренең «Дмитрий Бертман җитәкчелегендәге «Геликон-опера» Мәскәү музыка театры» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең әйдәүче сәхнә остасы, солисты **Тихомиров** Алексей Александровичка, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле вокалчы артисты (солисты) **Шәяхмәтова** Айгөл Рамил кызына, «Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе балет артисты (солисты) **Полодюк** Антон Сергеевичка **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Законлылыкны ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы **Волкова** Фәридә Рәхим кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Химия фәннәре докторы, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең электр-химия производстволары технологияләре кафедрасы мөдире **Дресвянников** Александр Федоровичка **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Композитор, «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең театр, кино һәм телевидение факультеты деканы **Галимова** Эльмира Мөнир кызына, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең сәхнәгә куючы рәссамы **Ибраһимов** Булат Фаил улына, рәссам-каллиграф, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең дизайн кафедрасы өлкән укытучысы **Сәләхетдинов** Ришат Назах улына, язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Харрасов** Ләис Мәүлет улына (Ләис Зөлкарнәйгә) **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең эрен хирургиясе бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы **Аржанова** Любовь Даниловнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең анестезиология-реанимация бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы **Борисова** Рәмзия Зариф кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының оештыру-методика эше буенча урынбасары **Мостафаева** Альмира Әнәс кызына, «Чирмешән үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Лашман фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире-акушеркасы **Шәйхетдинова** Җәмилә Мәсләхетдин кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәренең «Идел» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең спорт юнәлешендәге структур бүлекчәсе башлыгы **Борисова** Наилә Рөстәм кызына, Казан шәһәренең «Ракета» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Волков** Илһам Нурислам улына, Н.А.Зеленов исемендәге «Шинник» спорт комплексы» хосусый учреждениесе тренеры-укытучысы **Гәрәев** Илнар Гыйльметдин улына, Казан шәһәренең «Дельта» йөзү буенча олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Гарнышева** Эльвира Илдус кызына, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Ермолаев** Илдар Хәйрулла улына, «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Сәгыйров** Илнур Мингариф улына, Н.А.Зеленов исемендәге «Шинник» спорт комплексы» хосусый учреждениесе тренеры-укытучысы **Сәйфиева** Елена Юрьевнага, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының физкультура-спорт эше һәм проектларны гамәлгә ашыру бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Фролова** Елена Вил кызына, Казан шәһәренең «Дельта» йөзү буенча олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Чепик** Светлана Юрьевнага, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Васильево шәһәр тибындагы поселогының «2 номерлы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Шәрәфиев** Ралиф Раиф улына, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең самбо буенча тренеры **Шәрифҗанов** Марат Рәис улына, «Хезмәт резервлары» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль автоном учреждениесе административ-спорт корпусы баш инженеры **Шленов** Аркадий Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТИМӘСЕН ТИК ИСЛӘРЕ

Атна саен мунча керү инфаркт, инсульттан саклый, стресстан коткара. Япония галимнәре шулай дип ышандыра. Баксаң, мунча яратучылар арасында гриппка бирешүчеләр саны да дүрт тапкыр азрак икән. Мунча керү тагын нәрсәсе белән файдалы? Анда нәрсә эчәргә кирәк? Мунчада ис тисә, ни эшләргә?

Бу сорауларыбызга Казан дәүләт медицина академиясенең госпиталь һәм хастаханә терапиясе кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты Регина АХУНОВА ачыклык кертте.

vk.com

➤Мунча иң беренче чиратта кешенең иммунитетын ныгыта. Ник дигәндә, анда чакта кешенең тән температурасы 38–40 градуска кадәр күтәрелә. Бу исә – күп кенә авырулар башлангычы булган вирус һәм бактерияләрне юкка чыгару өчен менә дигән мөмкинлек. Мунча стресстан да коткара. Анда бөтен арыганлык бетә. Шул рәвешле кешенең психик халәте дә яхшыра. Мунчада бик нык тирләү аркасында организмдагы артык тоз һәм су бүленеп чыга. Тән тиресе йомшара, үлгән күзәнәкләрдән арынып, иркен сулый башлый. Югары һәм түбән температураларның чиратлашуы аркасында кан тамырларының сыгылмалылыгы арта, алар киңәя. Нәтиҗәдә кан әйләнеше дә яхшыра. Даими рәвештә мунча кергән кешенең йөрәк-кан тамыры системасы ныгый, миокард инфаркты килеп чыгу ихтималы кими. Мунча белән дус булганнарның баш миендәге кан әйләнеше дә, хәтере дә яхшыра.

➤Мунчада 2,5–3 сәгатьтән дә озаграк юынырга ярамый. Сау-сәламәт кешегә атнасына, күп дигәндә, дүрт тапкыр мунча керергә рөхсәт ителә. Хроник авырулары булган кешеләргә мунчага атнага бер тапкыр бару да җитеп тора. Бер керүдә 10–15 минуттан да озаграк парланып утырырга ярамый. Аны ял итү белән чиратлаштырып, 3–5 тапкыр кабатларга мөмкин. Парланып чыккач, салкынча су белән коенып алырга кирәк. Ник дигәндә, парланганда тир белән бүленеп чыккан матдәләр, тиз арада юып төшермәсәң, кибенә башлагач, тәнгә кабат сеңәргә мөмкин. Салкын су белән коенгач, артыннан ук җылымса су белән чайканып, тагын бер кат парланыр алдыннан 15–20 минут ял итеп алырга кирәк.

Ярый	Ярамый
✓Физик эштә хезмәт куйган, аз хәрәкәтләнгән кешеләргә, спортчыларга, һичшиксез, мунча керергә кирәк. Мунча буыннарны йомшарта, физик эш яки күнегүләр аркасында барлыкка килгән тән сызлау, авыртуны баса.	✕Температурасы күтәрелгән, эпилепсия, ишемия, яман шеш, бронхиаль астмадан интеккән, кан басымы югары булган, инсульт кичергән кешеләргә мунча керергә дә, чабынырга да ярамый. Тәне җәрәхәтләнгән, гемоглобины түбән булган кешеләр дә чабынудан тыелып торса хәерле. Йөкләлекнең башлангыч чорында эссе мунчага керү куркыныч.
✓Тир белән бүленеп чыккан судан соң калган булшлыкны тутыру өчен, мунчада күп итеп чиста, җылымса су эчәргә кирәк. Кишер, чөгендер соклары, куас, үлән чәйләре, кипкән җимешләрдән компот, морс һәм лимонад та файдага булачак. Аларны аз-азлап эчәсе.	✕Мунчада кара чәй, кәһвә һәм исерткеч эчемлекләр эчәргә ярамый. Соңгысы аеруча куркыныч. Исерткеч эчемлекләр аркасында кан тамырлары тагын да киңәя. Бу исә йөрәккә икеләтә авырлык килә дигән сүз.
✓Мунчада башка эссе сукмасын өчен, һәрчак башлыктан утырырга кирәк.	✕Утырып парланырга ярамый. Болай эшләгәндә, тәннең өске өлеше аякларга караганда ныграк җылыначак. Шулай итеп, йөрәккә икеләтә авырлык килә. Шуңа күрә мунчада ятып парланырга кирәк. Ул чакта гәүдә дә тигез җылына, буыннар да ял итә.
✓Мунчада чакта киңәш ителмәсә дә, ис тигән кешегә чәй яки кәһвә эчертергә ярый. Бу аның организмыннан агулы матдәне юдыру өчен кирәк. Кәһвә составындагы кофеин кан әйләнешен икеләтә тизрәк яхшырта.	✕Мунчада, чыныкмаган килеш яки йөрәк авыруы була торып, салкын су белән коенучылар бар. Болай эшләргә ярамый! Эссе мунчада кан тамырлары киңәя. Салкын су койгач, алар, киресенчә, кысыла. Шул рәвешле кан үзеннән-үзе башка йөгерә. Нәтиҗәдә баш авырта башлый.

➤Мунчага керер алдыннан җиңелчә ризык ашарга киңәш ителә. Ник дигәндә, эсседә ашказаны, эчәклекләр авыр эшли. Шул рәвешле ризык эшкәртү, үзләштерү авырлаша.

➤Мунчада чакта баш әйләнсә, җайлап кына салкын бүлмәгә чыгарга кирәк. Андый, чакта башны аска иеп, 5 минут утырып торырга киңәш ителә. Баш авыртса һәм әйләнсә, температура күтәрелсә, күңел болганса, эссе капкан дигән сүз. Андый чакта кешене, һавага алып чыгып, эскәмиягә яткырып, башына юеш чүпрәк куеп торырга, чиста су эчерергә кирәк. Аңын югалткан кешенең өстенә су сибәргә ярамый! Суның сулыш юлларына эләгүе бар. Андый чакта кичекмәстән табиб чакыртырга кирәк.

Гемоглобинны күтәрәбез!

Бер үк күләмдә яңа сыгылган кара торма, кишер, кызыл чөгендер, гранат соклары алып, барысын бергә болгатыгыз. Банкага бушатып, өстен каплап, 3 сәгать җылы духовкада тәнәтегез дә, суынгач, сөзегез. Сыекллыкны өсте ябылган савытта суыткычка куеп сакларга кирәк. Аны 2–3 ай дәвамында көнгә 3 мәртәбә ашарга ярты сәгать кала 2–3 аш кашыгы эчәләр.

Мондый төнәтмә дә әзерли аласыз: 1әр аш кашыгы вакланган миләш һәм гөлҗимешкә ике стакан кайнар су агызалар. Шуны сүрән утта 5 минут кайнаталар. Савытны калын сөлге белән төреп, бер тәүлек тоткач, сөзәләр. Аз гына бал салырга була. Төнәтмәне көнгә 3–4 мәртәбә ашар алдыннан яртышар стакан эчәләр.

Өчәр йөз грамм күрәгә, йөзем, каражимеш, инҗирне, кабыклы ике лимонны (төшләрен алырга) иттарткыч аша чыгаралар да, тәмено карап, бал салалар һәм барысын бергә яхшылап болгаталар. Катнашманы пыяла банкада суыткычта саклыйлар. Көнгә 3–4 тапкыр 1әр аш кашыгы эчәләр.

250 грамм башлы суганны ваклап турап, шуңа 200 грамм шикәр комы, ярты литр су салып, сүрән утта 2 сәгать тоталар, шуңа 2 аш кашыгы бал салып болгаталар. 1 ай дәвамында көнгә 2 тапкыр ашаганнан соң 1 аш кашыгы эчәләр.

Үзем сынадым

Чи чүпрә булышты

Кан басымым күтәрелеп тилмертә. Ун көн түбәндәге ысул белән дәвалангач, кан басымым рәткә килде. 100 граммлы чи чүпрәне тигез итеп 9 өлешкә бүләм дә, һәркайсын аерым кәгазьгә төреп, суыткычка куям. Һәр көнне кич, ятар алдыннан, бер өлеш чүпрәне савытка салып, шуңа бер аш кашыгы шикәр комы һәм чирек стакан су яки сөт салып, өстен калын чүпрәк белән ябып, төнгә калдырам. Иртән торгач, шушы массаны ач карынга эчәргә кирәк. Ярты сәгать вакыт үтүгә, иртәнге ашны ашарга мөмкин. Шулай итеп, тугыз көн дәваландым.

Асия ШӘРИПОВА. Балык Бистәсе

Аяк туңса...

✱Кан әйләнеше начар булган кешеләрнең аяклары туңа. Моңа кан тамырлары киңәю (варикоз) да сәбәпче булырга мөмкин. Калкансыман биз эшчәнлеге бозылганда да аяк туңа. Чәч тә тиз майлана, тырнаклар да сына башлый.

✱Аякны, туңганда, тозлы ванна ярдәмендә җылытырга мөмкин. Суга аш яки диңгез тозы кушарга, 2–3 аш кашыгы сөт һәм аз гына розмарин мае өстәргә кирәк. Җылыта торган компресслар да куярга мөмкин. Моның өчен аякка табаны спиртка манылган юка оекбаш, өстеннән йон оекбаш кияләр һәм юрган астында ятып торалар. Массажның да файдасы тия. Кышын урамга чыгар алдыннан бурсык мае сөртү дә ярдәм итәр.

✱Аягыгыз тиз туңучан булса, күннән эшләнгән, эче мехлы аяк киеме алыгыз. Болан, эт яки бүре мехыннан, сарык тиресеннән тегелгән итекләр бик суыкларда да аякны туңдырмый.

✱Кан әйләнеше бозылуга тиешенчә тукланмау, тәмәке тарту, физик активлык киму дә сәбәпче булырга мөмкин. Яшәү рәвешен, рационны үзгәртү, начар гадәтләрдән арыну, спорт белән шөгыльләнү дә хәлне яхшырта. Кан әйләнешен сарымсак, борыч, суган да җайга сала.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

«6 ЯШЕМДӘ ИКМӘК САЛДЫМ»

Казанда яшәүче Дагыстан кызы Раисат Абакарова милли ризыкларны яратып пешерә. Хисапчы белгечлегенә ия булса да, һөнәре буенча бер көн дә эшләмәгән ул. «Күңелем кечкенәдән кухняга тартылды», – ди пешекче.

Раисатка – 26 яшь. Иренең эше Казанга бәйле булгач, 3 ел элек монда яши башлаганнар. Инде ике ел Раисат заказга төрле тәм-томнар пешерү белән шөгыльләнә.

– Бу кызыксынудан гына башланып киткән эш иде. Башта әллә ни заказлар да булмады. Монда безнең Дагыстан халкының милли ризыгы чудуның нәрсә икәнен бик аз кеше белә. Кеше бит күбрәк белгән әйберенә, әйтик, пицца, суши, роллга өстенлек бирә, – дип сөйли Раисат. – Пешергән ризыкларымны социаль челтәрләргә куеп баргач, бераз шуннан күреп сорыйлар иде. Хәзер заказлар күбрәк «сарафан радиосы» аша килеп ирешә.

Шәһәр читенә күченгәч, бу эш белән ярты ел шөгыльләнми торган Раисат. «Күченү, ремонт эшләре, бала тәрбияләү мәшәкатьләре аркасында, бөтенләй вакыт булмады», – ди ул. Тик шулай да беркөнне үзе пешергән ризыклар белән күршеләрен сыйлап караган. Алар бик ошатып, мактау сүзләре әйткәч, сайлаган кәсебенә яңадан керешкән.

– Көненә 5–6, кайчакта 10–12 заказ алам. Каенанам белән бергә эшлибез. Ул миңа бик нык ярдәм итә, – ди пешекче. – Юка камыр эченә төрле эчлек салынган чуду әзерлибез. Гадәти пирогны, кыстыбыйны хәтерләтә ул. Аның эчлеге күптөрле: ит белән бәрәңге, кабак, эремчек тә салалар. Шулай ук төрле эчлекләр белән пилмәнгә охшаган курзе, хинкалилар да ясыйбыз.

Милли ризыкларда гына тукталып калмаган Дагыстан кызы. Былтыр кондитерлык курсларында белем алган. Пироглар, чуду һәм курзедан тыш, тортлар, меренга рулеты, чизкейклар да пешерә башлаган. Алга таба планнары да зурдан аның: киләчәктә рестораннар белән хезмәттәшлек итәргә җыена. Берничә тәкъдим дә килгән инде.

– Пешерү эше бала чагымнан ук күңелемә якын. Әле хәтерлим: беренче тапкыр 6 яшемдә икмәк пешереп караган идем. Тәҗрибәм зур, – ди, елмаеп, Раисат.

Ләйсән САФИНА

РАИСАТ АБАКАРОВАДАН ЧУДУ РЕЦЕПТЫ

Кирәк: *400 грамм чүпрәле камыр, камырга кушу өчен 1 стакан җылымса су (200 мл).*

Эчлек өчен: *400 грамм вак итеп туралган бәрәңге, 200–250 грамм ит, 1 суган, тәменчә тоз, тәмләткечләр.*

Диаметрын 30 сантиметр итеп, камырны уклау белән түгәрәкләп җәябез. Савытка бәрәңге, ит, суган, тоз, тәмләткечләр салып, барысын бергә яхшылап болгатабыз. Әзер җәемнең бер як яртысына юка гына итеп эчлекне җәеп, икенче яртысы белән каплыйбыз. 220 градуска кадәр кызган духовкага 40 минутка пешерергә куябыз.

Укучы киңәше

Картага бәйле лайфхаклар

Авылларда сугым чоры башланды. Мал эчәге, карталарны чистарту, куллану буенча укучыларыбыз «ВКонтакте» социаль челтәрендә киңәшләре белән бүлеште.

1 Малның ашказанын бушатабыз да, эченә җылы су салып, чайкап алабыз. Аннан соң бер чиләк кайнап торган суга бер пачка сода салабыз. Чиләктәге су ташып чыга, шуңа күрә соданы урамда салыгыз. Шул бер чиләк содалы кайнар суны карта эченә бушатабыз. Бөтен җиренә тиярлек итеп әйбәтләп селкетәбез. Әлеге суда 10–15 минут тотканнан соң, картаны бүлгәлибез. Болай эшләгәндә карта бик ансат чистартыла.

Фирдәүс МИРСӘЕТОВА

2 Картаны бөтен кеше дә ашамый хәзер. Без үскәндә, әниләр аннан өчпочмак пешерә иде. Шуны тәмле итеп бөтен гаилә бергә җыелып ашый идек. Искә алу бер рәхәт. Мин үзем ир-ат буларак, шул түбәтәе белән кырык картаны гына алам инде хәзер. Яхшылап салкын суда берничә кат югач, тагын бер ярты көнгә салкын суда тотам. Аннан кабат-кабат юам да, су, тоз, серкә өстәп, берәр төн кундырам. Болай иткәндә бик җиңел чистартыла.

Рәсим ХӨРМӘТОВ

3 Авыл җирендә яшәп, карта, эчәкне ташлаган кешегә исем китә. Минем дә балаларым ашамый, әмма кыш буе тавыклар рәхәтләнә. Чистартып тормыйм, яхшылап юып пешеклим дә иттарткычтан чыгарам. Пакетларга салып, туңдыргычка катырырга куям. Тансыклаган саен, җебетеп, тавыкларга бирәм. Көн саен бирсәң, ашамый башлыйлар, атнасына бер пакет салгач, рәхәтләнәләр йомырка салып.

Мәшүдә ХӘСӘНОВА

Белеп тор!

Кәеф күтәрә торган 3 күнегү

Көн буена кәеф өсти торган күнегүләр бар. Аларны иртән уянуга урыннан торганчы ясарга киңәш ителә.



1 нче күнегү. Йокыдан уянуга, яткан килеш аякларыгызны – аска, кулларыгызны өскә таба сузыгыз. Булдыра алганча киерелгәннән соң өч секунд чамасы шушы хәлдә торыгыз. Аннары тәнегезне ике секундка «йомшартып» алыгыз. Әлеге күнегүне биш тапкыр кабатлагыз. Аны ясау өчен нибары 25 секунд вакыт китә.

2 нче күнегү. Аркагызда яткан килеш, аякларыгызны балтыры ботка тиярлек итеп бөгегез. Оча сөяген, бераз гына аяклар белән этенеп, өскә күтәрегез. Әлеге халәттә өч секунд торыгыз һәм ике секундка тәнегезне «йомшартыгыз». Әлеге күнегүне дә биш тапкыр ясагыз.

3 нче күнегү. Яткан килеш корсак мускулларын катырыгыз һәм шул халәттә өч секунд торыгыз. Аннары тәнегезне ике секундка «йомшартыгыз». Әлеге күнегүне 5 тапкыр кабатлагыз, аны ясау өчен дә нибары 25 секунд вакыт кирәк булачак.

ЙОМШАККАЙДАН СОҢ ЧИСТАРТА

Йорт хайваннары йонынан келәм һәм җиһазлар чистартуның берничә уңайлы гына ысулы бар.

✓ Келәмне чистарту өчен, уч төбе кытыршы булган пирчәтка белән юешләп сөртеп чыгыгыз. Әлеге ысул белән кәнәфиләрне, диваннарны да чистартырга була.

✓ 1 стакан суга ярты стакан керләр өчен кондиционер салып, пульверизатор ярдәмендә келәмгә сиптереп чыгыгыз. Бераздан тузан суырткыч белән чистартып алыгыз. Келәмегез ялт итәчәк.

✓ Келәмне юеш каты себерке белән себереп алыгыз. Әлбәттә, болай бөтен йон да җыелып бетә дигән сүз түгел. Әмма ул өскә менгәнлектән, аны тузан суырткыч белән чистарту җайлырак булачак.

Бакчачыга

ТӘРӘЗ ТӨБЕМ САЕН ЛАЛӘ

14 февраль һәм 8 Мартка тәрәзә төбендә лалә чәчәкләре атсын дисәгез, аны нәкъ менә хәзердән дә калмый утыртырга кирәк. Утырту өчен тыгыз һәм эре суганчаларны сайлагыз. Электән сыналган гади сортларны сайласагыз, оттырмассыз. Әлбәттә, гибридлар матур, әмма бик көйсез. Суганчаны утыртканчы, аны зарарсызландырырга онытмагыз. Ә туфрагы җиңел һәм көпшәк булсын.

КЫШ БАБАЙНЫ КӨТӘСЕМЕ?

Мөселманга Яңа елны каршыларга ярыймы-юкмы? Елның-елында бәйрәм якынлашкан көннәрдә әнә шул сорау бәхәс уята. Балаларның Кыш бабайдан бүләк көтүе, чыршы тирәли әйләнүе дә – гөнаһ, дигән сүзләрне дә еш ишетергә туры килә. Бу сүзләрнең кайсы дөреслеккә туры килә дә кайсы арттырылган?

Яңа елга бәйле сорауларыбызга «Иске таш» мәчете имам-хатыйбы Рамил хәзрәт ЮНЫСОВ җавап бирде.

– «Еллар, гасырларның алышынуы» дигән төшенчә диндә бар. Хәтта Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Гасырлар, заманнар белән ант итәм», – ди. Ягъни Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән гасырлар, еллар, фасыллар үзгәрә. Әмма елларның берсеннән берсенә күчү вакыты безнең динебездә бәйрәм булып саналмый. Бездә шәригатьтә билгеләнгән бәйрәмнәр бар. Шул бәйрәмнәрдән тыш без динебезгә башка бәйрәмнәр кертә алмыйбыз. Ул – җомга көне, Корбан һәм Ураза гаетләре. Мәүлид ае, Кадер киче, Гарәфә көне кебек мөбарәк көннәр, төннәр, айлар бар. Ә менә Яңа елны каршылау бәйрәме безнең диндә каралмаган.

:: Мөселман балаларына чыршы бәйрәмендә катнашу, әйлән-бәйлән уйнау, Кыш бабайдан бүләк алу – гөнаһмы?

– Бу безнең эшсезлегебез һәм ялкаулыгыбыздан тора. Әгәр без Корбан, Ураза гаетләрендә балаларыбызга бүләкләр алып кайтсак, бергәләп өйне бизәсәк, аларны шушы күркәм бәйрәмнәребезгә ияләндерсәк, ул вакытта баланың күңеленә: «Әти-әни безгә елга ике мәртәбә зур бәйрәм оештыра», – дип сеңеп калачак. Әмма бу эш безнең үткән заманнарда эшләнмәде. Шуңа күрә безнең балалар бакчада, мәктәптә Яңа ел алдыннан үткәрелә торган чыршы бәйрәмнәре, Кыш бабайдан бүләк көтү, әйлән-бәйлән уйнау рухында тәрбияләнде. Әмма балага катгый рәвештә: «Чыршы бәйрәменә барма, ярамый, гөнаһ, хәрам», – дип әйтү дә дөрес булмас. Әкрен генә үзебезнең дини бәйрәмнәребезне киңрәк җәелдерсәк, хәерлерәк булыр.

:: Ел уңышлы булсын дип, бәйрәмдә бер-береңә ел символы төшерелгән сувенир, магнит бүләк итү дөресме?

– Юк, алар инде амулетка тиң әйберләр санала. Динебездә, ел уңышлы булсын дип, ниндидер сувенирлар бирешү бөтенләй хупланмый. Бу – ырым-шырым гына. Халык исә аңа бик тиз күнүчән. Без бар нәрсәне Аллаһы Тәгаләдән сорыйбыз. Тормышларның тыныч, тәннәрнең сәламәт, гаиләләрнең бәрәкәтле булуының төп сәбәпчесе – Аллаһы Тәгалә. Шуңа күрә ел алышкан вакытта, Яңа ел кичендә Аллаһтан: «Я Раббым, безгә киләсе елны хәерле, тыныч, бәрәкәтле кыл», – дип сорап, дога кыла алабыз.

:: Димәк, Яңа елда бер-береңә теләк теләү дә гөнаһ түгел?

– Юк, гөнаһ түгел. Әмма бер-береңне: «Бәйрәм белән!» – дип түгел, киләсе елларыбыз хәерле, имин булсын иде, дип тәбрикләү хәерлерәк.

:: Бәйрәм алдыннан мулдан табын әзерлибез. Бу ризыкларның күбесе икенче көнне үк бозылып бетә. Ул көннәрдә ашауда да чама хисе югала. Бәйрәм дип, берьюлы ике гөнаһка батабыз булып чыга түгелме?

– Без әлегә борынгыдан килгән йола белән яшибез. Яңа ел табынында һичшиксез оливье салаты белән мандарин булырга тиеш дигән гадәт тә шуннан килә. Мөселман кеше бу көндә ашап-эчеп утырыр урынга, ястү намазында дога кылып кайтыр да, Коръәннәрен укып, кунаклар килсә, алар белән сөйләшеп утырыр. Әмма традицион йола үтәлсен дип кенә Яңа елга сыгылып торган өстәл әзерләү дөрес түгел. Өстәлдә хәмер дә торса, икеләтә куркыныч. Бәйрәм көнне адәм балалары хәмер эчкәндә: «Без киләсе елның иминлеге өчен эчәбез», – диләр. Ә бит елның иминлеге – Аллаһы Тәгалә кулында. Димәк, алар Ходай каршында гөнаһ кыла булып чыга. Шуңа күрә тагын бер кабатлап әйтәм: безгә үзебезнең дини бәйрәмнәребезне пропагандаларга кирәк. Алар да Яңа ел кебек үк көтеп алынган,

Нияз Рахманның шәхси архивыннан

матур булырга тиеш. Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килгәч, пәйгамбәребездән: «И рәсүлаллаһ, менә яһүд халкы шундый зур итеп бәйрәм үткәрә. Безгә бу бәйрәмдә катнашырга ярыймы?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез дәшмәгән, әмма: «Мин ике бәйрәм – Корбан һәм Ураза гаете белән килдем», – дип, аларга сайлау мөмкинлеге тудырган.

:: Яңа ел алдыннан белгечләр елның нинди булачагын фаразлый башлый. Киләсе елга йолдызнамә төзелә. Аларга ышаныргамы?

– Йолдызнамә – йолдызларның безгә тәэсир итүенә ышану дигән сүз. Язмышыбызны да Аллаһы Тәгалә язмый, ә ул яраткан йолдызлыклар билгели булып чыга. Йолдызнамәләргә ышану безнең динебездә тыелган олуг гөнаһлардан санала. Йолдыз – үзе үк мәхлук. Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә безгә: «Мин җирдә һәм күктә булган бөтен планеталарны, йолдызларны яраттым», – ди. Шуңа күрә йолдызларны Аллаһы Тәгаләдән дә өстен куярга ярамый. Йолдызнамәләрне кем язган да, кем белгән, кем тикшергән соң? Аларда язылган һәр сүз – нигезсез мәгълүмат бит.

:: Быел Яңа ел чараларын уздыру-уздырмау уңаеннан бәхәс купты. Халыкның бер өлеше аларны кирәк дип саный, икенче берләре: «Уйнап-көлеп йөрер чак түгел», – ди. Бу уңайдан сезнең фикерне дә ишетәсе килә.

– Бездә төрле заманнар булды бит инде. Бөек Ватан сугышы, әфган сугышы вакытында да артистлар, егетләр янына барып, концертлар куеп, солдатларның күңелләрен күргәннәр. Шуңа күрә Яңа ел чаралары да халыкның күңелен күтәрү, бераз гына күтәренке рух бирү нияте белән үткәрелә, кирәктер. Әгәр халыкның күпчелеге: «Безнең хәзер уебыз бәйрәмдә түгел», – дип саный икән, аларга да каршы килеп булмый. Һәр кешенең – үз нияте. Яңа елны ничек каршы алаcын да, аны гомумән бәйрәм итәргәме-юкмы икәнлеген дә һәркем үзе хәл итәргә тиеш.

Хикмәтле янгын

Көчле давыл кубып, диңгездә йөзүче корабны батыра. Шул корабтагы бер кеше исән кала. Аны диңгез дулкыннары бер утрауга чыгарып ташлый. Бу кеше аңына килгәч, Аллаһка ялварып, ярдәм, котылу сорый башлый. Утраудагы кипкән агачларны җыеп, үзенә бер алачык ясап куя. Агачларның сусыл җимешләрен җыеп, куяннар аулап, азмы-күпме үзенә ризык таба.

Ә бер көнне алачыгы янына ризык әзерләү өчен учак яга да, тагын бераз чыбык-чабык җыеп килим, дип, агачлар арасына кереп китә. Кире кайтса... Ни күрсен, учак уты алачыгын да камап алган. Бу кеше: «Ни өчен, йә Раббым?» – дип үксеп елый башлый. «Ни өчен миннән шушы алачыгымны да алдың, йә Раббым? Бу дөньяда минем бер нәрсәм дә калмады бит инде хәзер. Шушы сәер утрауда берүзем калдым. Ни өчен миңа шулкадәр бәла-каза бирәсең?!» – дип хәсрәткә төшә.

Кич житкәч, янган алачыгы янына ятып йоклый. Ә иртән уянып киткәч, диңгездә бер кораб белән кечкенә көймәнең утрауга таба йөзеп килүен күрә. «Могҗиза! Нинди могҗиза бу?» – дип гаҗәпләнә бу кеше. Ә корабка утыргач: «Сез мине ничек таптыгыз?» – дип сорый. «Без бу утраудан чыккан төтенне күрдек һәм монда кеше бардыр, ярдәмгә чакырадыр дип уйладык», – диләр аңа.

Теге кеше шаккатып: «Йә Раббым! Алачыгым януына ничек көенгән идем. Ә ул минем котылуыма сәбәпче булган икән бит...» – ди.

Йәгез, бер дога!

БОРЧУ ҺӘМ КҮҢЕЛСЕЗЛЕКЛӘРГӘ КАРШЫ УКЫЛА

Ибне Габбас (р.г.) риваяте буенча, пәйгамбәребез (с.г.в.) борчулы вакытында болай ди иде:

«Лә иләһә илләллаһ үл-газыйм. Лә иләһә илләллаһ рабб уль-гарш илгазыйм. Лә иләһә илләллаһ рабб ус-сәмәүәти үә рабб уль-әрдый, рабб уль-гарш ил-кәрим».

Мәгънәсе: «Газыйм һәм Хәким булган Аллаһтан башка илаһ юк. Зур Гарешнең Раббысы булган Аллаһтан башка илаһ юк. Күкләрнең Раббысыннан, җирнең Раббысыннан һәм кыйммәтле Гарешнең иясе булган Аллаһтан башка илаһ юк». (Бохари: Дәгъват: 123)

Хәдис

Бернинди нигезсез кешеләр турында яман уйлаудан сакланыгыз, чөнки начар уй – сүзләрнең иң ялганы. Кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, көнләшмәгез, ачуланышмагыз, бер-берегезне ташламагыз, Аллаһының коллары булган хәлдә бер-берегезгә кардәшләр булыгыз!

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук. Тулы, дөрес итеп беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Саба районының Яңа Мичән авылыннан **Сөмбелә Ибраһимова** танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Мөнир Рахмаев башкаруындагы «Ә мин әле яшь», Ильмира Нагыймова репертуарыннан «Тимә йөрәгемә», Вадим Захаровның «Көттермәсәк иде әнкәйләрне» җырларын яшергән идек.*

Һәр яңа көн туган саен, җырны башкаручыдан «Яратасыңмы?» дип сорыйлар икән. Ә ул исә мәхәббәтне күңел белән тоярга өйрәнергә кирәк дип уйлый.

Әлеге җыр да – мәхәббәт категориясеннән. Бик бәхетле булыр өчен, җаннардагы сагышларны басар өчен, синең барлыгың турында да белү җитә, диелә анда.

Бу җыр исә – «йөрәгенә күпме наз сыйган» кадерле зат турында. Җырчы аңа «көтмәгәндә килә торган шатлыклар», «бәхетле картлыклар» тели.

ХОККЕЙЧЫ ФӘНҮЗӘ КАДЫЙРОВА:

«НӘФИС БУЛУГА ХОККЕЙ БЕРНИЧЕК ТӘ КОМАЧАУЛАМЫЙ»

Бүгенге сәхифәбезнең кунагы – безга тәүге тапкыр Кукмара районының Сәрдекбаш авылында басып, бүген Санкт-Петербургның «Динамо-Нева» хоккей командасында уйнаучы Фәнүзә КАДЫЙРОВА. Ике мәртәбә дөнья чемпионаты призеры, 2017 һәм 2019 елларда Универсиада җиңүчесе булган 24 яшьлек татар кызын «итәкле Овечкин» дип тә атыйлар. Без исә аның белән хоккейчы кызларга карата мөнәсәбәт, шәхси тормышы һәм иң зур хыялы турында сөйләштек.

:: Ни хәл?

– Бар да тәртип. Россия чемпионаты дәвам итә. Сишәмбе көнне бу елның соңгы уены булды. «Йолдызлар матчы» алдыннан бераз ял бирделәр, Кукмарага кайттым менә. Туган якларга соңгы тапкыр җәй көне кайткан идем.

:: Хоккей белән ничә яшьтән бирле шөгыльләнәсең инде?

– Беренче тапкыр тимераякка балалар бакчасына йөргән вакытта бастым. Биш-алты яшьләр тирәсе булгандыр. Ул чакта әти тренер иде. Кич белән мине бакчадан ала да үзе белән спортзалга алып кереп китә иде. Язгы-көзге кичләрем спортзалда йә көрәшеп, йә футбол уйнап, кышкылары бозда узды дияргә була. Минем беркайчан әни белән өйдә утырасым килмәде. Әти һәм абый нәрсә эшли, мин дә шуны эшләдем. Хоккей белән дә алардан күреп, аларга ияреп кызыксына, ә соңыннан шөгыльләнә башладым. Бу спорт төрен сайлавымның төп сәбәбе шулдыр. Абыем түгел, апам булса, нәрсә булыр иде икән – менә анысын күз алдына да китерә алмыйм.

:: Ә әниең каршы булмадымы?

– Юк. Әни, киресенчә, ничек тә ярдәм итәргә, рухландырырга тырышты. Мине ничек бар, шулай кабул итте. Бүген дә шулай. Мин, гомумән, әти-әниемә һәрнәрсәдә ирек биргәннәре өчен бик рәхмәтле.

:: Хоккей күбесенчә ирләр уены булып санала. Мондый мөнәсәбәткә карата нинди фикердә син?

– Һәркемнең үз фикере инде. Холкым буенча, мин – начарга да, яхшыга да тиз ышана торган кеше. Шуңа күрә бу уңайдан берәүнең дә фикерен тыңламаска тырышам. Хатын-кызлар хоккее – спортның бер төре. Ул Олимпия уеннары исемлегенә дә керә. Мин исә бары тик күңелемә хуш килгән, үзем яраткан спорт төре белән шөгыльләнәм. Һәм мин аннан ләззәт алам. Калганы мөһим түгел.

:: Ничек кенә булса да, хоккей – физик яктан авыр спорт төрләренең берсе. Хоккей уйнап, хатын-кызга хас нәфислек, нәзакәтлелекне саклап калып буламы, синеңчә?

– Кешенең үзеннән торадыр ул. Дөресен генә әйткәндә, бу турыда уйланганым юк иде әле. Хатын-кызлар лигасы барыбер үзгә бит ул. Без ир-ат хоккейчылар кебек үк сугышмыйбыз. Булса да, сирәк кенә инде *(көлә)*. Безнең уенда физик көчкә караганда тактика мөһимрәк. Җанатарлар да күбрәк тактик уен, ниндидер кызыклы комбинацияләр карарга килә. Юкка гына Россиядә хатын-кызлар лигасын «матур лига» дип атамыйлардыр инде. Кыскасы, нәфис һәм нәзакәтле буласың килсә, хоккей моңа берничек тә комачауламый. Миңа калса, бу фикерем белән башка хоккейчы кызлар да килешәдер.

:: Фәнүзә, хоккейдагы позицияң – һөҗүмче. Тормышта да һөҗүмчеме син?

– Хоккей уйный башлаганнан бирле һөҗүмче мин. Башка позиция турында уйлаганым һәм хыялланганым булмады. Ә тормышта... Элек тыйнаграк идем. Хоккей шулай йогынты ясыйдырмы, хәзер башкалар белән аралашу да, яңалыкларны кабул итү дә җиңелрәк бирелә. Миңа хәзер үземне үстерү, камиллеккә омтылу елдан-ел кызыграк.

:: «Йолдызлар матчы»ның барысында да чыгыш ясагансың икән. Иң яхшы уенчылар сафында булу җаваплылык өстиме?

– Хәзер бу турыда артык уйланмыйм. Мин – уенчы, һәм мин үз уенымнан ләззәт алам. Иң мөһиме шулдыр. Ниндидер статистика алып бармыйм, нәтиҗә артыннан кумыйм. Моны җаваплылык дип түгел, ә тиешле нәрсә дип кабул итәм. Шул ук вакытта ул миңа тагын да яхшырак булырга этәргеч бирә.

Блиц-сораштыру

– Иң хөрмәт иткән уенчың?
– Алар икәү – Кирилл Капризов һәм Коннор Макдэвид.
– Хоккейчыларга ашарга ярамаган, әмма син бик тә яраткан ризык бармы?
– Юк. Әмма мин өч ел элек ит ризыкларын бөтенләй ашамый башладым. Шәп икән ул!
– Гадәттә, иртәң ничек башлана?
– Иртәмне рәхмәт сүзләреннән һәм ниятләрдән башлыйм.
– Иң зур хыялың?
– Олимпия медале.

:: КХЛда кем өчен җан атасың?

– КХЛның да, НХЛның да уеннарын карап барам. Хәзерге вакытта өч команда – «Торпедо» (Түбән Новгород), СКА (Санкт-Петербург) һәм «Ак барс» (Казан) өчен җан атам. «Торпедо» – КХЛның зур ачышы, миңа калса. СКА командасын үзем дә Петербургта чыгыш ясаганга түгел, талантлы уенчылары һәм аларның системалы уеннары өчен күзәтеп барам. Ә «Ак барс» – минем өчен кадерле клуб. Үзебезнекеләр бит! Бу хис балачактан килә. Элек әти белән, йә булмаса гаиләбез белән хоккейга бару бик зур һәм шатлыклы бәйрәм булып истә калган.

:: Хатын-кызлар лигасында татар кызлары шактый. Алар белән аралашасыңмы?

– Һәрвакыт аралашып торам, дия алмыйм. Уеннарда, җыеннарда очрашсак, әлбәттә, аралашабыз.

:: Фәнүзә, гаилә кору турында уйланасыңмы?

– Гаилә кору турында кем генә хыялланмый икән? Әлбәттә, мин дә бу турыда уйланам. Ләкин миңа бүгенге тормышым кадерле, миңа менә хәзер рәхәт. Гел хәрәкәттә, юлда булу, гомумән, актив тормыш алып бару бик рәхәт. Билгеле, бераз ардыра да, ләкин бу гына хоккейга карата мәхәббәтемне юкка чыгара алмый. Һәрнәрсәнең – үз вакыты. Сәгате суккач, уйлап торырга да туры килмәс, гаиләле булып куярмын әле.

7 декабрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар.Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12
09.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК» 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
14.15 «Туган авылым» 6+
14.45 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
17.00 «БИЧАРАКАЙ» 12+
18.00 «Халкым минем…» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00 «Спортивная среда» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники». В плену слухов. Абдулла Баттал 12+
00.15 «Рыцари вечности». Державин 12+
00.30 «Фолиант в столетнем переплете» 12+
00.45 «Таяну ноктасы» 16+
01.10 «Җырлыйк әле!» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05. 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30, 00.15 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
18.50, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости с субтитрами
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45, 03.05 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
21.00 «Время»
21.45 Памяти Сергея Пускепалиса. «ШИФР» 16+
22.45 «Большая игра» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Вести. Местное время
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Вести. Местное время
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.05 Вести. Местное время
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-22» 16+
22.25 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров и Екатерина Кистень в телесериале «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15, 14.50, 21.55 Новости
06.05, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.45, 14.55 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола». Прямой эфир
12.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Обзор 0+
16.55 Спортивная гимнастика. «Кубок олимпийского чемпиона Михаила Воронина». Прямая трансляция из Москвы
18.55, 21.20 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
19.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА (Москва) – «Астана» (Казахстан). Прямая трансляция
22.40, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины «Факел» (Новый Уренгой) – «Локомотив» (Новосибирск) 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.20 «Англия – Россия. Коварство без любви». «Сепаратизм с британским акцентом» 16+
01.35 «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+
04.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведемся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.05, 01.10 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Вороне перо» 16+
13.40, 00.05 «Знахарка» 16+
14.15, 00.35 «Верну любимого» 16+
14.50 «ОТПУСК В СОСНОВОМ ЛЕСУ» 16+
19.00 «АКВАМАРИН». Начало 16+
20.30 «Шаг в карьеру» 16+
20.35 «АКВАМАРИН». Продолжение 16+
23.00 «Порча». «Писк». «Забери меня» 16+
02.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 3-я и 4-я серии
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ФРОНТ ЗА ЛИНИЕЙ ФРОНТА». 1-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00, 15.05 «БАТЯ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Холодная война. Битва экономик». 3-я серия 16+
19.40 «Секретные материалы» 16+
22.55 «Между тем» 12+
01.10 «СХВАТКА» 12+
02.45 «Мария Закревская. Драматургия высшего шпионажа» 12+
03.40 «Сделано в СССР» 12+
03.55 «БАТЯ» 1-я и 2-я серии 16+

8 декабрь | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар.Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12
09.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 00.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Туган авылым» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Авангард» – «Ак Барс». Прямая трансляция 6+
19.00 «Точка опоры» 16+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 12+
00.50 «Видеоспорт» 12+
01.15 «Соотечественники». Магуба Сыртланова 12+
01.40 «Рыцари вечности». Гаяз Исхаки 12+
01.50 «Фолиант в столетнем переплете» 12+
02.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ Шоу» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30, 00.15 «Халкым минем» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
18.50, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Яралы язмышлар». Хәсән Туфан 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости с субтитрами
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45, 03.05 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
21.00 «Время»
21.45 Памяти Сергея Пускепалиса. «ШИФР» 16+
22.45 «Большая игра» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Вести. Местное время
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Вести. Местное время
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
21.05 Вести. Местное время
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-22» 16+
22.25 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров и Екатерина Кистень в телесериале «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 11.45, 15.10, 21.55 Новости
06.05, 15.45, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.50 Биатлон. Pari Кубок России. Спринт. Мужчины. Прямая трансляция из Тюмени
10.15 «Вид сверху» 12+
10.45 «Оазис футбола». Прямой эфир
11.50 Биатлон. Pari Кубок России. Спринт. Женщины. Прямая трансляция из Тюмени
13.05, 22.40, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
15.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. 1/8 финала. Обзор 0+
16.25 Хоккей. Фонбет. Чемпионат КХЛ. «Авангард» (Омск) – «Ак Барс» (Казань). Прямая трансляция.
18.50 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «ПАРМА-ПАРИ» (Пермский край). Прямая трансляция
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Енисей» (Красноярский край) – УНИКС (Казань) 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
00.20 «Поздняков» 16+
00.35 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
01.30 «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+
04.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

05.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. КРЫМ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30 «ПРИКАЗ: ПЕРЕЙТИ ГРАНИЦУ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 16+
13.25 «Не факт!» 12+
13.50, 14.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. КРЫМ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
20.40 «Ступени Победы». «Ночные ведьмы «Севастополя» 16+
21.25 «Код доступа». «Невидимая война российского спецназа» 12+
22.15 Новости дня 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Легенды кино» Анатолий Кузнецов 12+
23.35 «АТЫ-БАТЫ, ШЛИ СОЛДАТЫ…» 12+
01.05 «РОДИНЫ СОЛДАТ» 12+
02.35 «НА ПУТИ В БЕРЛИН» 12+
04.00 «Москва – фронту». Док. сериал 12+
04.20 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. КРЫМ» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БАТЯ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ФРОНТ ЗА ЛИНИЕЙ ФРОНТА». 2-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00, 15.05 «БАТЯ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Холодная война. Битва экономик» 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» 12+
01.15 «ОПАСНЫЕ ТРОПЫ» 12+
02.15 «ВЗЯТКИ ГЛАДКИ» 16+
04.00 «Военный врач Валентин Войно-Ясенецкий» 16+
04.40 «Москва – фронту» 16+
05.00 «БАТЯ». 5-я и 6-я серии 16+

9 декабрь | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар.Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12
09.00 «КАЙДА СИН?» 12+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 Телефильм 12+
14.45 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Житезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
17.00 «БИЧАРАКАЙ» 12+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 6+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00 «Юлчы» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «БИНГО БОНГО» 16+
00.00 «Соотечественники» 12+
00.25 «Рыцари вечности». Федор Шаляпин 12+
00.50 «Фолиант в столетнем переплете» 12+
01.05 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05 «Ком сәгате» 12+
09.40, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – Казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Яралы язмышлар». Хәсән Туфан 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
17.30 «Калеб» 6+
18.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.15 «Туган җир» 12+
19.40 «Заман көзгесе» 6+
20.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
21.25 «АЛДЫМ-БИРДЕМ» 12+
00.40 «Калеб» 6+
01.05 «БАЛА БАЛАСЫ БАЛДАН ТАТЛЫ» 12+
04.15 «Ком сәгате» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости с субтитрами
09.20 «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 02.10 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос. Дети» возвращаются 0+
23.20 Екатерина Васильева, Сергей Газаров, Алексей Веселкин в фильме «АНИМАТОР» 16+
01.15 «СУДЬБА НА ВЫБОР» 16+
05.00 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Вести. Местное время
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Вести. Местное время
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
21.15 Вести. Местное время
21.30 Музыкальное гранд-шоу. «Дуэты» 12+
23.45 «Улыбка на ночь». Программа Евгения Петросяна. 16+
00.50 Олеся Грибок, Александр Пашков, Дмитрий Панфилов, Алексей Симонов и Юлия Кудояр в фильме «Я НЕ СМОГУ ТЕБЯ ЗАБЫТЬ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.10, 14.50, 17.00 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.45, 14.55 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола». Прямой эфир
12.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Обзор 0+
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
05.20 Дзюдо. Кубок России. Трансляция из Калининграда 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
09.25, 10.35 «Следствие вели…» 16+
11.00 «Запчасти для человека» Научное расследование Сергея Малоземова 12+
12.00 «ДедСад» 0+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «ПРАКТИКАНТ-3» (S) 16+
00.00 «Своя правда» 16+
01.55 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.20 «Квартирный вопрос» 0+
03.10 «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+
04.40 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведемся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.05, 01.10 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Злобник» 16+
13.40, 00.05 «Знахарка». «Запретный плод» 16+
14.15, 00.35 «Верну любимого» 16+
14.50 «АКВАМАРИН» 16+
19.00 «БЛИЗКО К СЕРДЦУ». Начало 16+
20.30 «Шаг в карьеру» 16+
20.35 «БЛИЗКО К СЕРДЦУ» 16+ Продолжение
23.00 «Порча». «Гниль». «Ходок» 16+
02.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+

ЗВЕЗДА

06.40 «БАТЯ» 7-я и 8-я серии 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 23.55 «ФРОНТ В ТЫЛУ ВРАГА» 12+
13.20, 15.05 «БЛАГОСЛОВИТЕ ЖЕНЩИНУ» 1-я - 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.55 «Легенды госбезопасности» 16+
19.55 «СВОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ, ЧУЖОЙ СРЕДИ СВОИХ» 12+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.00 «Музыка+» 12+
02.45 «ОПАСНЫЕ ТРОПЫ» 12+
03.45 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+
05.05 «Военный врач Александр Сахаров» 16+

10 декабрь | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Разил Вәлиев 12 +
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.30 «Казаннан – Казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Татар халык җырлары» 0+
14.00 «АЛМАШ» 12+
16.00 «БӘБИ» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ-Шоу». Эльмира Нигъмәтова 12+
23.00 «ЗДРАСЬТЕ, Я ВАШ ПАПА» 12+
00.35 «АВГУСТ» 18+
02.35 «Вехи истории». От ТатЦИКа до КабМина 12+
03.00 «Каравай». Мой Татарстан. Камерный оркестр «Ренессанс» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Яралы язмышлар». Хәсән Туфан 12+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 12+
17.10 «Казаннан – Казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Үзгәреш җиле-2017» 6+
23.10 «ИСТӘЛЕК ӨЧЕН ГЫЙЛЕМХАНГА» 12+
01.30 «Синең җырларыңны көйләп...» Әлфия Авзалованың туган көне уңаеннан 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00, 18.00 Новости с субтитрами
10.15 «ПроУют» 0+
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Бог войны. История русской артиллерии» 12+
13.45 «Все, что успел» 12+
14.25, 03.35 К 95-летию со дня рождения Владимира Наумова. «БЕГ» 12+
18.20 «Снова вместе. Ледниковый период» 0+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.40 «НОТР-ДАМ» 16+
01.25 «Великие династии. Пушкины» 12+
02.20 «Моя родословная» 12+
03.00 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Доктор Мясников» 12+
12.35 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 Премьера. Елена Полянская, Анатолий Руденко, Евгений Парамонов, Ксения Бабкина и Лариса Кулакова в фильме «ЛЕКАРИ ДУШ» 12+
01.05 Мария Баева, Александр Тютин, Андрей Сенькин и Виктория Тарасова в фильме «ВОПРЕКИ ВСЕМУ» 12+
04.20 Людмила Курепова, Антон Макарский, Андрей Барило, Елена Захарова, Александр Лазарев-мл. и Александр Пороховщиков в фильме «КОГДА ЦВЕТЕТ СИРЕНЬ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.45, 17.00 Новости
06.05, 14.50, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.50 Биатлон. Pari Кубок России. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Тюмени
09.45, 12.40, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.50 Биатлон. Pari Кубок России. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Тюмени
15.25 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – ЦСКА. Прямая трансляция
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Дзюдо. Кубок России. Трансляция из Калининграда 0+

НТВ

05.00 «Спето в СССР» 12+
05.45 «ИНСПЕКТОР КУПЕР» (S) 16+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 0+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Секрет на миллион» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» 16+
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. СИМБИРСКИЕ МОРОЗЫ» (S) 12+
23.30 «Международная пилорама» 16+
00.15 «Квартирник НТВ у Маргулиса» (S) 16+
01.35 «Дачный ответ» 0+
02.30 Сериал «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+
04.00 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.05, 06.30 6 кадров 16+
06.50 «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ». Начало 16+
10.30 «Шаг в карьеру» 16+
10.35 «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ». Продолжение 16+
11.00 «ТРИ СЕСТРЫ». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 69-я – 72-я серии 16+
22.30 «ТРИ ИСТОРИИ ЛЮБВИ» 16+
02.15 «ТРИ СЕСТРЫ». 1-я – 4-я серии 16+
05.15 «Нотариус» 16+

ЗВЕЗДА

05.40 «ДОЖИВЕМ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА» 12+
07.30 «День образования ФГАУ «Патриот» 16+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.20, 04.25 «ВОЛШЕБНАЯ ЛАМПА АЛАДДИНА» 6+
10.00, 01.35 «НЕПОДДАЮЩИЕСЯ» 12+
11.45 «Легенды музыки» 12+
12.10 «Легенды телевидения» 12+
13.15 «Время героев» 16+
13.35 «Главный день». «Сикстинская Мадонна и маршал Иван Конев» 16+
14.20 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
15.10 «Не факт» 12+
15.35 «Война миров» 16+
16.25 «СЛУЧАЙ В КВАДРАТЕ 36-80» 16+
18.30 «ВЫСОТА 89» 16+
21.00 «Легендарные матчи» 12+
00.00 «СВОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ, ЧУЖОЙ СРЕДИ СВОИХ» 12+
02.55 «ПРАВО НА ВЫСТРЕЛ» 12+
04.15 «Сделано в СССР»

11 декабрь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 Илсоя Бәдретдинова концерты 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 «Зебра полосатая» 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Эльвира Әхмәтова 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.20 Зәйнәб Фәрхетдинова концерты 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Инновации в будущее. 50 лучших инновационных идей для Республики Татарстан» 12+
14.00 «АЛМАШ» 12+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
16.00, 00.35 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Разил Вәлиев 12 +
23.00 «СОЛНЦЕВОРОТ» 16+
01.30 Зәйнәб Фәрхетдинова концерты 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00, 02.45 «Адымнар» 12+
07.30 «Мәңгелектән исә җил». Ләис Зөлкарнәйнең 60 яшьлек юбилей кичәсе 6+
09.30 «Әдәби галәмгә тәрәзә...» Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин турында телеочерк 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «ӨЧ АЯКЛЫ АТ» 6+
13.50 «Әдәби хәзинә» 12+
14.30 «Өмет йолдызы». Эльмира Калимуллина концерты 6+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
22.00 «Үзгәреш җиле-2018» 6+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.15 «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь». Ркаил Зәйдулланың юбилей кичәсе 12+
05.40 «Шаян хәлләр» 12+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.10 «БЕГ» 12+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.00, 12.00 Новости с субтитрами
10.15 «Жизнь своих» 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.15 «Голос наших побед» 12+
13.20 Легендарные фильмы Михаила Козакова. «БЕЗЫМЯННАЯ ЗВЕЗДА» и «ПОКРОВСКИЕ ВОРОТА» 12+
18.25 Михаил Задорнов 16+
19.10 «Поем на кухне всей страной» 12+
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» 16+
23.45 «Романовы» 12+
00.45 «Камера. Мотор. Страна» 16+
02.05 «Моя родословная» 12+
02.45 «Наедине со всеми» 16+
03.30 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

06.15 Карина Андоленко, Агния Кузнецова, Елена Шевченко и Алексей Комашко в фильме «АРИФМЕТИКА ПОДЛОСТИ» 16+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 16.00 Вести
11.50 Алла Юганова, Кирилл Гребенщиков, Екатерина Вуличенко и Павел Крайнов в фильме «ЛУЧШАЯ ПОДРУГА» 12+
17.00, 19.00 «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
18.00 «Синяя Птица»
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
01.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
02.30 Карина Андоленко, Агния Кузнецова, Елена Шевченко и Алексей Комашко в фильме «АРИФМЕТИКА ПОДЛОСТИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Магомед Анкалаев против Яна Блаховича. Прямая трансляция из США
08.00 Профессиональный бокс. Теренс Кроуфорд против Давида Аванесяна. Бой за титул чемпиона мира по версии WBO в полусреднем весе. Трансляция из США 16+
08.50 Биатлон. Pari Кубок России. Масстарт. Мужчины. Прямая трансляция из Тюмени
09.55, 13.05, 15.10 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
12.05 Биатлон. Pari Кубок России. Масстарт. Женщины. Прямая трансляция из Тюмени
17.15, 22.00 Новости
17.20 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
19.55 Профессиональный бокс. Евгений Тищенко против Йоури Каленги. Прямая трансляция из Екатеринбурга
22.05 Все на Матч! Прямой эфир
22.35 Хоккей. Фонбет Матч Звезд КХЛ. Трансляция из Челябинска 0+
00.45 «Один день в Катаре» 16+
01.10 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
03.15 Бокс. Bare Knuckle FC. Роландо Дай против Announcement Сангмуанга. Трансляция из Таиланда 16+
05.20 Дзюдо. Кубок России. Трансляция из Калининграда 0+

НТВ

05.00 «ИНСПЕКТОР КУПЕР» (S) 16+
06.35 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.20 «Суперстар! Возвращение» Новый сезон (S) 16+
23.15 «Звезды сошлись» 16+
00.50 «Основано на реальных событиях» 16+
03.25 «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ТРИ ИСТОРИИ ЛЮБВИ» 16+
10.25 «В ОДНУ РЕКУ ДВАЖДЫ» 16+
10.30 «Шаг в карьеру» 16+
10.35 «В ОДНУ РЕКУ ДВАЖДЫ» 16+
14.40 «БЛИЗКО К СЕРДЦУ» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 73-я – 76-я серии 16+
22.30 «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ» 16+
02.15 «ТРИ СЕСТРЫ». 5-я – 8-я серии 16+
05.15 «Нотариус» 16+
06.05 6 кадров 16+

ЗВЕЗДА

05.50 «СЛУЧАЙ В КВАДРАТЕ 36-80» 16+
07.00 «ВЫСОТА 89» 16+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы». «Альманах №122» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии». Серафим Меркулов 12+
13.05 «Специальный репортаж» 16+
13.40 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ». 1-я – 4-я серии 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ...» 12+
01.20 «ДОЖИВЕМ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА» 12+
03.00 «Москва – фронту» 16+
03.20 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ» 1-я и 2-я серии 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 5 декабрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Рабит Батулла. «Кичер мине, әнкәй» Г. Камал ис. ТГАТ спектакленең радиоварианты
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 6 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Лирик концерт

Чәршәмбе, 7 декабрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Татар композиторларының маршлары

Пәнҗешәмбе, 8 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар». Венера Шарипова язмалары

Җомга, 9 декабрь

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на башкирском языке).
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Георгий Ибушев җырлый

Шимбә, 10 декабрь

8.10 «Сәнгатебез тарихы сәхифәләре». Әдәби-музыкаль программа
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Писатели – детям»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Диас Вәлиев. «Намус хөкеме». Г.Камал ис. ТДАТ спектакле. 1 нче өлеш

Якшәмбе, 11 декабрь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.10,16.10 Диас Вәлиев. «Намус хөкеме». Г. Камал ис. ТДАТ спектакле. 2-3нче өлешләр

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Сәрия МИФТАХОВА

КЕМ ЭШЛӘМИ – ШУЛ УКЫМЫЙ

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Ак яка»лар заманы үтеп бара: илгә төзүче, инженер, авиаконструктор, табиблар кирәк. Киләсе елдан әлеге белгечләрне күбрәк әзерли башламакчылар. Моның өчен мөмкинлекләр бармы?

Яңарту

Россия Хөкүмәте, ел саен төбәкләрнең тәкъдимнәрен исәпкә алып, целевиклар, ягъни максатчан белем алучылар өчен квоталар исемлеге билгели. 2023 елда кирәкле белгечләр исемлегеннән күренгәнчә, табибларга ихтыяҗ зур. Әйтик, «дәвалау эше» юнәлешендә урыннарның 75 проценты «целевик»ларга бирелгән. «Педиатрия»дә бу күрсәткеч 76 процентны тәшкил итә. Акушер-гинеколог, онколог, кардиолог, эндокринолог, хирургларны да күбрәк әзерли башлаячаклар. Вузларда болай да табибларны максатчан әзерләүгә зур игътибар бирелә. Әмма Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин белдергәнчә, урыннарны арттыру хастаханә, шифаханәләрдәге кытлыкны бетерергә булышмаган. Аның фикеренчә, булачак табибларны укыганда ук эшкә урнаштырып, торак, өстәмә түләүләр белән тәэмин итәргә кирәк. Шулай ук очкычлар җитештерү, тимер юл транспорты юнәлешләрендә дә урыннарны юмарт бүлгәннәр. Бакалавриаттагы бюджет урыннарының яртысы социаль-мәдәни, китапханә тармагына туры килә. Халыкара багланышлар, журналистика өлкәсендә исә «целевик»лар санын киметкәннәр.

Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары Ирина Яровая сүзләренә караганда, ил икътисадында кадрлар кытлыгы 37 процентны тәшкил итә икән. Вуз тәмамлаучы яшьләрнең яртысы үз белгечлеге буенча эшләми. «Целевиклар»ны әзерләү исә кадрлар өлкәсендә тигезлекне сакларга ярдәм итәчәк дип ышана белгечләр.

Һөнәрләр әзерләү исемлегендә Россиянең яңа территорияләре – Луганск, Донецк Халык Республикалары, шулай ук Херсон, Запорожье өлкәсендәге ихтыяҗ да исәпкә алынган. Аларга төзүчеләр, архитектор, метеоролог, географлар да кирәк. Кораблар төзү, авиатөзелеш юнәлешләре буенча белгечләр дә узган ел белән чагыштырганда 10 процентка күбрәк сорала. Дәүләт Думасының Икътисади сәясәт комитеты җитәкчесе урынбасары Станислав Наумов белдергәнчә, белгечләр белән тәэмин итү иске предприятиеләрне яңарту, яңаларын төзү мөмкинлеге бирәчәк. Яшьләр максатчан укытуга бирелгән квоталардан уңышлы файдаланыр, дип өметләнә ул.

Сүз уңаеннан, «целевик»лар диплом алгач, туган ягына кайтып, ким дигәндә өч ел эшләргә тиеш. 2023 елның 1 сентябреннән максатчан уку турында килешү төзегән студентларга таләпләр үзгәрергә мөмкин. «Целевик»ның нинди билге алырга тиешлеген аны укырга җибәрүче хәл итәчәк. Әгәр баллары түбәнрәк булса, студентның стипендиядән мәхрүм ителүе, ахыр чиктә хәтта укудан да куылуы бар.

Шартлары бармы?

Казан илкүләм тикшеренүләр техник университетның (КАИ) реактив двигательләр һәм энергетик җайланмалар кафедрасы мөдире Алексей Лопатин – республика мәктәпләрендә инженерлар сыйныфлары ачкан мөгаллим. Андый сыйныфлар Казанда, шулай ук республиканың сигез районындагы мәктәпләрдә эшли.

– «Бал» дип кенә авыз балланмый. Инженерлар кирәклеге турында соңгы дистә елда еш ишеттек. Чит илләрнең санкцияләр кертүе бу белгечләрне әзерләүне тизләтәр дип уйлыйм. Көтәргә вакыт юк. Без Көнбатыш очкычларында очтык. Хәзер уянып киттек, ә үзебезнең техника юк, – ди Алексей Лопатин. – Элек инженерлар артыгы белән әзерләнде. Бу начар түгел, аның каравы иң яхшысын сайлап алу мөмкинлеге бар иде. Бөтен кешегә дә инженер булырга димәгән. Лириктан физик ясап булмый. Моның өчен булачак инженерларның һөнәрне төптән уйлап сайлавы мөһим. Кайбер егетләр моңа армиягә бармас өчен яки әти-әнисе кушканга гына укый. Шул ук вакытта үз эшенең остасы булган юрист, икътисадчылар да кирәк. Яхшы юридик хезмәт күрсәтү үзәге эзләгәндә, таба алмый интегәсең бит. Бөтен профессияләр җитәрлек булганда гына, җәмгыять төрле яктан үсә.

Аның фикеренчә, хикмәт күпме урын бүлеп бирүдә түгел, инженерларны сыйфатлы итеп әзерләүдә. Моның өчен бу эшкә мәктәптән үк тотынырга кирәк. Республикада университетларның кадрлар әзерләү мөмкинлеге бик югары. Бюджет урыннары да күп. Бу сан хәтта мәктәпне тәмамлаучы чыгарылыш укучылары кадәр.

– Бездә, яшьләрнең барысы да югары белемгә омтыла, дигән фикер яши. Юк, алай түгел. Аларның яртысы гына вузларга бара, – ди Алексей Лопатин. – Безгә яшьләр теләп килә. Үз кафедрам буенча саннар китерә алам, быел 65 студентны – бакалавриатка, 18ен магистратурага кабул иттек. Авиатөзелеш буенча саннар күбрәк.

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты галиме, юллар оешмасы җитәкчесе Мөхәммәт Гатиятуллин белдергәнчә, укыту гына түгел, шартлары да кирәк.

– Укыту шартлары да икенче бит хәзер. Элек студент белгеч булып чыкса, хәзер бакалавр, тагын ике елдан соң магистр. Биш ел укыту дөрес әйбер иде. Фәннәр дә тирәнтен өйрәтелде, практикага да күбрәк урын бирелде. Инженерлар әзерләү өчен бик отышлы бу. Укып бетергәч, эшкә урнашу да мөһим. Яшь белгеч кая бара, нишли? Элекке вакыттагыча юллама буенча җибәрүне дә хуплыйм мин. Элек студент үзенең сукмагын, карьера үсешен белә иде. Әйтик, башта мастер, прораб, участок начальнигы, аннан җитәкче… Менә шуннан кире чигенми иде. Кызганыч, бу әйбер югалды. Белгеч югалып кала. Аларны әзерләү өчен мөмкинлекләр бар. Кая китсен инде ул? Юлы, төзелеш оешмалары – барысы да үз урынында. Укыту программасын тагын бер кат карап чыгарга кирәк, – ди Мөхәммәт Гатиятуллин.

Вузларда 20 мең 689 урын бар

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан әйтүләренчә, киләсе елга әнә шуның кадәр урын бар.

– Бюджет урыннары 2022 ел дәрәҗәсендә сакланган. Ихтыяҗга караганда, киләсе елда югары белемле кадрлар әзерләүгә дәүләт заказы 3,5 мең кешене тәшкил итә. Медицина хезмәткәрләренә (дәвалау эше һәм педиатрия), физик культура, IT белгечләргә, инженерлык кадрларына ихтыяҗ зур. Максатчан укыту буенча студентлар саны мәгариф оешмалары тарафыннан 1 июньнән дә соңга калмыйча исәпләнәчәк, – дип белдерделәр матбугат үзәгендә.

Фикер

Дамир ХАҖИЕВ, Мамадыш районы баш табибы:
– Табибларга ихтыяҗ һәрвакыт бар. Башка районнар белән чагыштырганда, бездә кирәкле белгечләр тупланган диярлек. Барлыгы 80 табиб булса, шуның 12се – декрет ялында. Менә шуның белән бераз кыенлык туа. Бүген төрле медицина вузларында районнан 100дән артык студент белем ала. Шуларның 20се – «целевик»лар. Быел өч белгеч кайтты. Хәзер бөтенесенә Казан кирәк, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама да ярамый. Алты ел укыйлар да, күзләре томалана, берсенең дә районга кайтасы килми башлый. Кызыксындыру чараларына килгәндә, торагы да бар, район башлыгы җир дә бирә. Ташламалы кредитлардан да файдаланырга була. Арендага бирү өчен үзебезнең икешәр бүлмәле сигез фатир бар. Берсе әлегә буш тора, реаниматолог киләчәк. Хирург, участок терапевтлары, анестезиологка кытлык бар. Авылларда фельдшерлар олыгая, елга 1–2 «целевик»ны урнаштырырга тырышабыз. Кызлар, кияүгә чыгып төпләнеп калмаса, китү ягын карый. Минемчә, табиблар җитмәү проблемасын максатчан укыту белән генә хәл итеп була. Укыганнарның да урыннарга барып җитүе кирәк.

Сан

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан хезмәт базарындагы ихтыяҗ турында сораштык.

– «Россиядә эш» платформасында Татарстан буенча **53** меңнән артык вакансия тәкъдим ителгән. Хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты **0,16** процентны тәшкил итә. Бу **– 1** эшсезгә **6** вакансия туры килә дигән сүз. Бүген бигрәк тә машина йөртүчеләр (**1641**), инженерлар (**1273**), табиблар (**881**), пешекчеләр (**830**), эретеп ябыштыручылар (788), кондукторлар (804), шәфкать туташларына (**624**) ихтыяҗ бар. Әйтик, машина йөртүчеләргә – **39** мең **594**, инженерларга – **36** мең **821**, табибларга **36** мең **855** сум хезмәт хакы тәкъдим ителә. Шәфкать туташлары, кондуктор, пешекчеләргә исә **23–28** мең сум вәгъдә ителә, – диделәр министрлыкта.

БЕЗГӘ КЕМНӘР КИРӘК?

Җитештерү өлкәсендә – 17,9 мең (33,8%)
Төзелеш, күчемсез милек – 6,7 мең (12,7%)
Транспорт – 3,4 мең (6,4%)
Мәгариф һәм фән – 2,6 мең (4,9%)
Сәламәтлек саклау – 2,6 мең (5%)
Сату һәм хезмәт күрсәтү – 2,2 мең (4,1%)
Азык-төлек сәнәгате өлкәсе – 2,1 мең (4%)
Консалтинг – 2 мең (3,7%)

КАГЫЛМЫЙ УЗ, ВИРУС!

bigstockphoto.com

Грипп килә! Республика табиблары шулай дип чаң суга. Быел ул аеруча авыр узачак, дип кисәтә алар. Ник дигәндә, республикада дуңгыз гриппы йоктыру очраклары да күзәтелергә мөмкин, дип фаразлыйлар. Соңгы арада Татарстанда ОРВИ белән авыручылар да арта бара. Коронавирус дигән зәхмәтнең дә, китә алмаган кунак кебек, безнең арада яшәп яткан көннәре. Ничек сакланырга?

Бүген үк әзерләнәсе

Яшерен-батырын түгел, соңгы ике ел ярым вакыт эчендә тормышыбызда коронавирустан башка бер генә чир дә калмаган кебек тоела башлаган иде инде. Елның-елында кышкы чорда күзәтелә торган грипп та беткән сыман булды. Рәсми саннардан күренгәнчә, коронавирус башланган 2020 елда Татарстанда грипп йоктыруның бер генә очрагы да теркәлмәгән. 2021 елда нибары бер кешегә шундый диагноз куелган. Быел исә бу сан белән генә чикләнмәбез, дип фаразлыйлар. Узган атнада Татарстанда грипп йоктыруның беренче очрагы теркәлгән инде. Ил күләмендә исә бу күрсәткеч 70не тәшкил итә.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков сүзләренә караганда, быел республикага A (H1N1) штаммлы дуңгыз гриппы килер дип көтелә. Бездә ул соңгы тапкыр 2009 елда ук күзәтелгән.

– Әлеге аның ниндидер үзгә билгеләре турында сөйләргә иртәрәк. Хәтерләсәгез, 2009 елда дуңгыз гриппы бигрәк тә йөкле хатын-кызларга зур зыян салган иде. Без 2,5 ел дәвамында коронавируска каршы көрәштек. Шуңа безнең халыкның иммунитеты ныгыгандыр, гриппка да каршы тора алырбыз дип өметләнәм, – дип белдерде министр «ВТ» хәбәрчесенә.

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсендә исә бу уңайдан тынычланырга иртәрәк дип кисәтәләр. Идарә җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина фикеренчә, республикада грипп һичшиксез таралачак һәм ул, алдагы еллар белән чагыштырганда, күпкә авыррак узачак.

– Соңгы ике елда республикада грипп йоктыру очраклары күзәтелмәде диярлек. Шул рәвешле халыкның иммунитеты кимеде. Күпләрнең организмы әлеге чиргә каршы торырга әзер түгел. Шуңа күрә якын арада грипп йоктыру очраклары кискен артырга мөмкин, – дип фаразлый белгеч.

Авдонина сүзләренә караганда, грипп котырган чорда йөкле хатын-кызларга, балаларга, коронавирус белән авырып сихәтләнүчеләргә, 65 яшьтән өлкәнрәк кешеләргә аеруча сак булырга кирәк. Чирдән саклану өчен иң нәтиҗәле чара дип гриппка каршы вакцина ясатуны атый ул. Тик аны республикада яшәүчеләрнең 37 проценты гына ясаткан. Узган атнада республикага гриппка каршы вакцинаның 110 мең дозалык соңгы партиясе кайтты. Белгечләр, бу мөмкинлектән файдаланып, чиргә каршы бүгеннән үк чарасын күреп куярга киңәш итә.

Пәри башка, җен башка

Алда телгә алынган дуңгыз гриппы нәрсәсе белән куркыныч соң? Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары, Казанның сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, аның инкубация чоры бик кыска. Дуңгыз гриппы күп дигәндә ике көн эчендә кешедән кешегә иярә. Аны берничә сәгать эчендә дә эләктерергә мөмкин.

– Дуңгыз гриппы йоктырган кеше үзендә иң элек хәлсезлек тоя, башы авырта, бөтен гәүдәсе, буыннары сызлый, күз дә кисеп-кисеп авыртырга тотына. Алга таба кисәк кенә тән температурасы күтәрелә, баштарак коры булган ютәл юешкә әверелә. Дуңгыз гриппын башкалардан аерып торган иң төп билге – алда телгә алынганнары белән беррәттән кешенең эче авырта, эче китә, ул коса. Бу аңлашыла да. Дуңгыз гриппы – организмны агулый торган вирус. Шуңа организм шул рәвешле әлеге агудан котылырга тырыша. Иң гаҗәбе шул: ашказаны, эч авыртудан гадәттә эчкән дарулар да бу очракта булышмый. Дуңгыз гриппын ахыргача дәвалап бетермәсәң, бик җитди өзлегүләр дә күзәтелергә мөмкин, – ди белгеч.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының эпидемиология һәм иммунопрофилактика буенча баш белгече Дмитрий Лопушов исә соңгы арада социаль челтәрләрдә таралган имеш-мимешләргә ачыклык кертте. Ул сүзләргә ышансаң, дуңгыз гриппы туберкулезның яшерен формасы булып чыга. «Бу – уйдырма. Әлеге ике чир арасында бернинди бәйләнеш тә юк», – дип белдерде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Тагын бер зәхмәт

Бер атна эчендә Татарстанда ОРВИ белән авыручылар саны 11 процентка арткан. Бу күрсәткеч эпидемик чиктән 13 процентка югарырак. Коронавирус та тормышыбыздан китәргә ашыкмый. Любовь Авдонина сүзләренә караганда, ковид белән авыручылар саны 19 сентябрьдән кими башлаган. Республикада әлеккечә үк «омикрон» штаммы өстенлек итә (95 процент). Коронавирусның яңа чыккан «цербер» штаммына килгәндә, Татарстанда әлегә аның бер генә очрагы теркәлде», – ди Авдонина.

Белгечләр, «цербер» штаммы бик тиз тарала, дип кисәтә. Ул «омикрон» штаммы вакытындагы кебек билгеләр (тамак авырту, борыннан агу, 38 градуска кадәр күтәрелгән югары температура, көчле ютәл, тын кысылу, баш авырту һ.б.) белән уза. Шулай да кеше аны «дельта» штаммы белән чагыштырганда җиңелрәк уздыра.

Белгечләр коронавирус белән янәшә йөргән тагын бер зәхмәтле вирус турында да истән чыгармаска куша. Табиблар аны метапневмовирус дип атый. Ул өске сулыш юллары зарарланудан гыйбарәт. Узган ел вируслы авырулар котырган чорда республикада метапневмовирус йоктыруның нибары ике очрагы гына булса, бүген инде шундый 57 очрак теркәлгән.

– Әлеге вирус бик тиз арада үпкәләргә төшә. Кешедә бронхит, бронхопневмония китереп чыгара. Өч яше тулмаган, аллергиядән интеккән балалар өчен аеруча куркыныч ул. Метапневмовирус вакытында көчле ютәл, бизгәк борчый, тын кысыла, баш авырта, эчәклек эшчәнлеге дә бозылырга мөмкин. Ни кызганыч, әлеге инфекциягә каршы вакцина да юк. Шуңа балада алда телгә алган билгеләрнең берсе генә булса да күзәтелсә дә, кичекмәстән чарасын күрергә, баланы бакчага, мәктәпкә җибәрмәскә кирәк, – ди Любовь Авдонина.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«ҮЗ БЕЛДЕГЕҢ БЕЛӘН ДӘВАЛАУ КУРКЫНЫЧ»

Соңгы арада балалар арасында да авыручылар саны кискен артты. Балалар бакчасындагы төркемебездә бүген, әйтик, 26 баладан 5 бала гына иде. Сабыйларның күбесе эч авыртудан зарлана, тән температурасы 39–40 градуска кадәр күтәрелә. Грипп билгеләреме бу? Баланы вируслы чирдән дәвалаганда, ата-ана нинди хаталардан сакланырга тиеш? Шул сораулар белән 11 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе педиатры, Татарстанның атказанган табибы **Гөлназ АЗИЗОВА**га мөрәҗәгать иттек.

:: Гөлназ Хәйдәровна, балалар арасында авыручылар ни сәбәпле арта?

– Моңа, иң беренче чиратта, һава торышының кисәк үзгәрүе сәбәпче. Кояш яктысы җитми, моңа кадәр урамда дымлы һава торышы сакланды. Бакчага йөрүче балалар бик күп. Күбесе әле аңа яңа иләшеп кенә килә. Күп кенә баланың авыруы бакчага иләшү чорын узуы белән дә бәйле. Шул сәбәпле безгә дә көненә икеләтә күбрәк баланы кабул итәргә туры килә.

:: Бүген күп кенә балалар югары температура, эч авыртудан тилмерә. Бу – грипп билгеләреме?

– Әлегә балалар арасында бер генә грипп очрагы да күренмәде. Әмма ике-өч балада аңа охшаш билгеләр күзәтелде. Аларның тән температурасы бик югары, эч авыртудан зарланалар. Тән темпертурасы югары булганда эч авырту – гадәти күренеш. Шуңа күрә ул бала грипп белән авырмаганда да күзәтелергә мөмкин. Әгәр югары температурадан тыш, баланың эче китә, коса башласа, бу балага эчәклек инфекциясе эләккән дигән сүз. Андый чакта кичекмәстән инфекция хастаханәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Балада грипп икәнлеген ничек чамаларга?

– Ковидтан аермалы буларак, грипп вакытында баланың тән температурасы бик югары була. Коронавирус вакытында ул 38 градус тирәсендә тирбәлсә, грипп вакытында 39–40 градуска җитә. Ул бик авыр төшә, биш көн чамасы саклана. Гриппның беренче көнендә бала тамак авыртудан зарлана, калтырый башлый. Икенче-өченче көнгә инде берөзлексез борчып торучы коры ютәл пәйда була. Борынга томау төшә. Эч авыртудан да зарланырга мөмкин. Борыныннан агып, күзләре яшьләнсә, балада ОРВИ дигән сүз.

:: «Ашыгыч ярдәм»не кайчан чакырырга?

– Күп кенә ата-ана, баланың температурасы 37,5кә күтәрелүгә үк, «ашыгыч ярдәм» чакыра. Әмма бу очракта өйгә участок табибын чакыру да җитә. «Ашыгыч ярдәм» хезмәткәрләре, иң беренче чиратта, авыр хәлдәге балаларга, тәнен көзән җыерган, ниндидер катлаулы авырулары булган, өянәге кузгалган сабыйларга ярдәмгә ашыга. Юк кына температура өчен чакыру аркасында, алар күпкә җитдирәк ярдәм кирәк булган бала янына барып җитә алмаска мөмкин.

БАЛАНЫ ВИРУСЛЫ АВЫРУДАН ДӘВАЛАГАНДА, НИНДИ ХАТАЛАРДАН САКЛАНЫРГА?

➤Бала авырый башлауга, күп кенә ата-ана башта аны үзлегеннән генә дәвалап маташа. Табиб янына килгәндә инде хәлләр мөшкелләнгән була. Дәвалау дөрес башланмагач, баланы ахыргача дәвалап бетерү дә бик кыен.

➤Ата-аналар арасында, бала авырый башлауга ук, аңа антибиотик эчертә башлаучылар шактый. Эчәк инфекциясе вакытында шундук эчәк антибиотигы бирүчеләр дә бар. Бу даруларны табиб белән киңәшләшкәч кенә эчерергә ярый.

➤Баланың температурасы күтәрелгән икән, димәк, организм вирусларга каршы көрәшә башлаган дигән сүз. Шуңа күрә температураны 38,5 градустан артып киткән очракта гына төшерергә кирәк.

➤Температурасын төшергәндә, тирләсен өчен, баланы калын киендерергә, юрганга төрергә ярамый. Алай эшләгәндә, аны хәтта көзән җыерырга да мөмкин. Температура төшкәндә, тәннең кызулыгы парга әйләнә. Шуңа күрә баланың өсте ачык булырга тиеш. Подгузникларны да салдырып торырга кирәк. Бүлмәне җилләтеп, дымландырып, балага күп итеп су эчерергә дә онытмагыз.

➤Еш авырый икән, димәк, баланың иммунитеты какшаган, дип саный күпләр. Чынлыкта исә, вируслы чирләр белән авырганнан соң даими рәвештә риносинусит, үлекле отит, пиелонефрит кебек өзлегүләр булып торган баланың гына иммунитеты какшаган дип санала. Әгәр бала елга 10–12 тапкыр авырый һәм өзлегүләрсез генә терелеп бетә икән, димәк, аның иммунитеты бик яхшы.

ЯМАН ШЕШ БЕЛӘН АВЫРГАН ЛИЛИЯ:

«УЛ ЧИР БЕЛӘН ДУСЛАШЫРГА КИРӘК»

Көчле рухлылар

Без рак авыруының исемен тутырып әйтергә дә куркабыз. Кайберәүләр «өч хәрефле авыру», кемнәрдер «әшәке чир», күпләр «теге зәхмәт» дип тә атап йөртә. Ә 39 яшьлек Лилия Казанская аннан курыкмаска киңәш бирә. Вакытында табибка бару, бөтен карарны тиз кабул итү аны үлемнән йолып кала. Әле бит күзләренә карап, «әнием» дип торучы ике кечкенә баласы да бар.

– Быел март аенда кулым ялгыш кына күкрәгемә тиеп китте. Ниндидер каты әйбер барын тоеп алдым. Кат-кат кулымны йөртеп карыйм. Күңелгә шик керде. Тизрәк табибка чаптым. Әле аңа да чират иде. Ә миңа тиз кирәк. Казанның бер түләүле клиникасына язылып алдым. Табиб карады, анализлар алды. 10 көннән хәбәр көтәргә кушты. Ул көннәрне ничек үткәргәнне хәтерләмим дә, – ди Лилия.

Анализ нәтиҗәсе куандырмый. Табиблар Лилиянең күкрәгендә яман шеш барлыгын әйтә. Ул нишләргә дә белми. Үлемнән курку хисе барлыкка килә. Лилиянең башында бер генә уй: «тиздән үләчәкмен». Куркудан гәүдәсе катып кала хәтта. Гәүдә белән бергә күңел дә ката. Ни елый, ни көлә, ни кешеләр белән сөйләшә алмый ул. Бер атна шулай йөри. Шуннан соң Лилиянең психолог һөнәре эшкә керешә.



– Үземне селкетеп уятып җибәрдем. Син нишлисең, Лилия?! Балаларың бар бит. Алга таба яшәргә кирәк, дим. Күзләр ачылып киткәндәй булды. Шул көнне мин бик озак еладым. Ялгыз гына уйларымны рәткә китерә алмасымны аңладым. Онкопсихологка язылдым. Әкренләп тынычланып, чирне кабул итәргә, аның белән яшәргә өйрәнә башладым, – ди Лилия. – Үземне кулда тотарга өйрәндем. Ник мин елап утырырга тиеш соң әле? Табибым бар, операция ясатам, аннары кирәкле дәвалану алам, дим. Матур киемнәремне киеп, бизәнеп, кая да булса барам. Өйдә ялгыз гына калмый идем. Үз дусларым да, иремнекеләр дә мине һәрчак аңлады. Хәлемә керделәр. Алия исемле дустыма мин аеруча рәхмәтле. Теге чакта ул мине шулкадәр дөрес юлга керткән икән. Бер дә ташламады. Минем белән гел башка темаларга сөйләшер иде. Яман чир хакында бер сүз искә төшермәде. Мин аны хәзер яхшы аңлыйм.

Лилиягә бер клиникада эшләүче танылган табиб операция ясый. Аннары ул Республика клиник онкология диспансерында дәвалана. Чит илгә барып, акча түләп дәвалануга караганда, үзебездә бушлай медицина ярдәменә ышана. Андагы табибларның, шәфкать туташларының кешегә булган яхшы мөнәсәбәтен сокланып сөйли. Дөрес, химия терапиясе алу җиңел булмый. Аннан соң ашыйсы килмәү, күңел болгану, исләр, тәмнәр сизмәү… Авырлыктан елый, үзенә шулай рөхсәт итә. Айга бер тапкыр кычкырып еласа да була. Ә башка көннәрне елмаерга, ничек кенә авыр булса да сабыр итәргә, тормышка сөенеп яшәргә тырыша.

– Бу чир белән очрашкач, күп әйберләрне аңладым. Табиблар куйган диагнозны кабул итәргә кирәк. Шул халәтне тоярга, синә ничек кенә куркыныч булмасын, моны кабул итәргә кирәк. Бар да үзеңнән тора. Кеше йә үлемне, йә яшәүне сайлый. Үлемне сайлыйсың икән, 2–3 ай узганны көтәсең дә китеп барасың. Яшим, дисең икән, сынауларны җиңеп, каршылыкларны узып, тормышка тотынасың. Яшәүне сайлагач, янында синә ярдәм итәрдәй кешеләр барлыкка килә башлый, – ди Лилия. – Рактан куркырга кирәкми. Аның белән дуслашырга кирәк. Синә бу чир бирелгән икән, димәк, ул тиккә генә килмәгән. Сез кайдадыр дөрес эшләмәгәнсез. Шушы урынны табарга кирәк. Күңелне чистарту мөһим. Яңадан яши башлагыз. Шкафтагы иң матур чәй сервизын чыгарып куегыз, матур күлмәкләр киегез, яңа туган көнгә сөенеп яшәгез. Үзегез дә сизмәстән, җиңеллек киләчәк. Бәхеттә яшәсәгез, яман чир сездән үзе китәчәк. Табиблар да ракның кортизон белән туклануын әйтә. Димәк, стресс кичерүчеләрне ул тиз эләктереп алачак. Шуңа күрә, үзегезнең хисләрне чамада тотыгыз!

Лилия яман чиргә каршы көрәшкән вакытта ире белән аерылыша. Әмма бу аны тагын да ныгыта. Балалары бар бит. Кызына – 8 генә, улына – 7 яшь. Аларга әни бик тә кирәк. Аңа күпләр, син бик көчле, диләр икән. Әмма Лилия үзен көчле дип уйламый. Ул бары тик яши. Күңеле кушканча яши хәзер. Сабыйлары исә әниләренә яшәү көче бирә.

– Яман чир белән очрашкан күп кенә кешеләрнең якыннары белән сөйләшәм. Кемнеңдер апасы авырудан соң биш ел яшәгән. Кемдер: «Әни өч кенә ел торды», – дип җавап бирә. Мин шул арада тиз генә күңелдән балаларым яшенә биш елны кушам. 13 һәм 12. Юк, алар әле кечкенә була. Мин аларны ташлап китәргә тиеш түгел. Үземә «озак яшәргә!» дигән күрсәтмә бирәм, – ди ул. – Хәзер инде финанс, юридик, психолог белемем өстенә, коуч һөнәрен сайладым. Нәкъ менә яман чир белән очрашкан кешеләрнең җанын дәвалыйсым килә. Аларга киңәшләр бирәсем, чир белән очрашкач, ничек яшәргә кирәклеген аңлатасым, чирне җиңәргә өйрәтәсем килә. Без чирдән түгел, ул бездән куркып торсын!

«Башка чарам калмады»

Казанда яшәүче 3 яшьлек Риназ Зиннәтуллинга ярдәм кирәк. Сөйләшә алмый, бер колагы начар ишетә, кыенлык белән генә йөри.

– Авырлы вакытта гел тикшеренеп тордым. Ул чакта кибеттә эшли идем. Авыр да күтәрелде. Бала төшү куркынычы да булды. Әмма дәваланып чыккач, бар да яхшы, диделәр. Сабыемны үз вакытында таптым. Аны ярып алдылар, – дип сөйли әнисе Айзирә. – Баштарак баланың утырмавына, үрмәли алмавына игътибар иттем. Табиблар борчылмаска кушты. Аларның сүзенә ышанып, тынычланып калдым. Тик хәлебез тагын да начарланды. Яңадан табиблар янына чаптым. Алар исә улымда ДЦПның бер төрен таптылар. Риназның нерв системасына да зыян килгән.

Хәзер Айзирә улы белән тернәкләнү курслары уза. Файдасын сизәбез, ди ул.

– Моңа кадәр туганнарым булышты. Инде алардан ярдәм сорарга да уңайсыз. Үзем әлегә өченче балам белән декретта утырам. Балага кайчак түләүле дәвалану курслары да алырга туры килә. ЛФК, массажлар кыйммәт тора. Хәзер менә баламны яңадан тикшерә башладылар. Бер анализ өчен 35 мең сум сорыйлар. Мин балалар белән өйдә генә булгач, тормышны ирем алып бара. Әмма ул акча гына җитми, – ди Айзирә. – Моңа кадәр чит кешедән ярдәм сораганым юк иде. Әмма башка чарам калмады. Баламны яңадан тикшертеп, аны аякка бастырасым килә.

Риназга булышырга теләүчеләр әнисе Айзирә Айдар кызы Зиннәтуллинаның **89655965191** телефон номерына беркетелгән Саклык банкы картасына акча сала ала.

Рәхмәтле эш

Актаныш районының Колын авылында яшәүче 75 яшьлек Фәндәлия апаны, гомер иткән йорты яшәрлек хәлдә булмагач, картлар йортына җибәрергә телиләр. Мәрхәмәтле авылдашлары аны алып кала.

Яшәргә яраклы йорт табалар да, аны шунда күчерәләр. Бу эштә Иске Айман җирлеге башлыгы Марсель Әхмәтхановның өлеше аеруча зур.

– Фәндәлия апа ялгызы гына яши. Өе бик искергән иде инде. Хәтта җимерелү куркынычы да бар иде. «Нигә аңа фатир бирмисез?» – дип тә әйтүчеләр булды. Әмма физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр өчен бушлай фатир каралмаган. Әгәр андый мөмкинлек булса, бирмәс идекме, – ди ул. – Ялгыз яшәгәч, өстәвенә авыру да булгач, без аңа һәрдаим ярдәм итәргә тырыштык. Иганәче дусларым аша да күчтәнәчләр бирә идек. Йортының начар булуы да бик борчыды. Дуслар белән бергә кечкенә генә бер йорт салып булмасмы дигән идек. Әмма барып чыкмады. Ярдәм итәм, дигән якын кешем кинәт үлеп китте. Мәшәкатьләр артты. Шулай итеп, Фәндәлия апага без авылдан башка йорт эзләргә булдык.

Алар Фәндәлия апа яшәгән йорт каршысындагы буш торган өйгә туктала. Анда яшәгән Вәяфис абый күптән вафат икән. Хәзер ул йортка аның апасы Флүрә Сәрвәрова хуҗа. Ул ике дә уйлап тормый, ризалаша. «Рәхәтләнеп яшәсен. Ул йорт безгә кирәк түгел бит әле», – ди.

Авылдашларга бер эндәшү җитә. Иң элек алар, җыелып, Вәяфис абый яшәгән йортны тәртипкә китерә. Кеше тормаган йортка төзекләндерү кирәк була.

– Авыл кешеләре белән йортның түбәсен алыштырдык. Акчаны иганәчеләр дә бирде, авылдашлар да җыйды. Инде бар да тәртиптә дисәк, газ тоташтыру белән проблемалар килеп чыкты. Шуннан соң без Фәндәлия апага электр казаны алып куйдык. Ул акчаны күп чутламый, өйне дә җылы тота. Бөтенебез бергәләп Фәндәлия апаны иске йортыннан күчердек. 2 ай булды инде, – ди Марсель Әхмәтханов.

Авылдашларның күңеле шулкадәр киң була – алар яңа нигездә Коръән ашына кадәр уздыра. Матур, чиста, җылы, тәзек йортта яшәүче Фәндәлия апа көн туган саен рәхмәтен укый. Үзен тәрбияләп торган социаль хезмәткәр Кифаяга, күршеләре Зиннур белән Эльвирага да бик рәхмәтле ул.

– Сәламәтлегем мактанырлык түгел. Шөкер, авылыбыз фельдшеры ташламый үземне. Хәлемне белешеп тора. Кирәк икән, дарулар бирә, укол ясый, – ди Фәндәлия апа. – Мин мондый йортта яшәрмен димәгән идем инде. Флүрә Сәрвәровага, авыл җирлеге башлыгына, миңа ярдәм иткән һәр кешегә чиксез рәхмәтлемен. Үзләре дә рәхәт яшәсеннәр!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ИЛДАР ЯГЪФӘРОВ:

«ТАТАР КИНОСЫ КЕМГӘ КИРӘК?»

Россия кинематографистлары берлегенең Татарстан бүлеге рәисе Илдар ЯГЪФӘРОВ белән кино өлкәсе проблемалары турында сөйләштек. Борчылырга урын бар. Кино заллары ярым буш, ә Россия фильмнары аз күрсәтелә. Федераль прокатка чыккан Татарстан картиналары гомумән бер-ике генә. Ни өчен «Исәнмесез?» прокатка чыга алмый? Яки Татарстанның башка режиссерлары эшләре нигә күренми? Баксаң, милли киноның проблемалары бу гына да түгел икән әле.

:: Элек «Ни өчен үзебезнең кино кинотеатрларда юк?» дигән сорауга, анда чит ил фильмнары белән эшлиләр, дип җавап бирәләр иде. Хәзер чит илнеке дә юк, үзебезнеке дә күренми. Хикмәт нәрсәдә?

– Фильмнар бар. Ләкин бөтен кино залларының да ихтыяҗын капларлык санда түгел. Әмма бу хәл дистрибьютерларның элеккечә эшләве нәтиҗәсендә дә шулай килеп чыга. Чөнки алар һаман да халыкны көлдерә торган аттракцион-фильмнарны җыя. Ә уйландыра торган, фәлсәфи фильмнар прокатка эләкмичә кала. Дөрес, тирән эчтәлекле фильмнарга башка төрле тамашачы йөри. Әмма бит мондый фильмнар да залны тутыра! Дөресен әйтим, «Исәнмесез?» белән прокатка чыгарбыз дип уйлаган идек. Әмма минем үз дистрибьютерым юк. Хәер, прокат белән шөгыльләнүче аерым кешеләр бар.

:: Татарстан фильмнары прокаты белән кем шөгыльләнергә тиеш?

– Минемчә, «Татаркино» оешмасы үз фильмнарын гына түгел, Татарстанда төшерелгән барлык фильмнарны прокатка чыгару турында кайгыртырга тиеш. Мин дә кул кушырып ятмаячакмын, билгеле. Ләкин монда да проблемага килеп төртеләсең. Әйтик, шул ук «Исәнмесез?» фильмын интернеттагы кино платформаларына чыгару җиңел түгел. Мисал өчен, «Okko» онлайн кинотеатрына җибәреп карыйм, алар: «Сезнең хокукларыгыз «Татаркино»да бит», – диләр. Кинематографистлар фильмнары белән «Татаркино» шөгыльләнергә тиеш, гамәлдә башкача килеп чыга.

Кызганыч, бу оешмада соңгы 30 елда шушы өлкәдә белеме булган бер генә кеше дә эшләмәгән. «Татаркино», фильм производствосы, кинофестиваль язмышы – бер кеше кулында һәм бу аяныч. Бер кеше бөтен эшне колачлый алмый. Бөтен эшне дә үзең эшләгәндә, фәкать үзең белән генә шөгыльләнәсе килеп тора. Ә моннан тулы бер өлкә зыян күрә. Үзең кино төшергәч, башкаларныкы күзгә күренми. Аларны прокатка да чыгарасы килми. Кабат әйтәм: «Татаркино» ул Татарстан киносының әти-әнисе кебек, үзенекен генә түгел, бөтен картиналарны да яратырга тиеш. Хәзер шундый кулай вакыт: бөтен фильмны да кино залларына чыгарырга мөмкинлек бар.

:: Татарстанның прокатка чыгарлык фильмнары күпме?

– Елына бер-ике яхшы фильм төшерелә. Сыйфат яхшырды, аны барысы да күрә. Яңа картиналардан, мин Рәхимбайның «Микулай» фильмының прокат тарихы яхшы булыр дип уйлыйм. «Әпипә» дә – зур прокатка чыгарлык фильм. «Исәнмесез?»нең дә потенциалы бар. Һәрхәлдә, ул Татарстанда кызыксыну уятты. Хәзер Татарстаннан читтә, аерым урыннарда иҗади очрашулар оештырабыз. Әйтик, 4 декабрьдә ул Чукоткада күрсәтеләчәк.

:: Иҗади очрашулар белән фильм үз чыгымнарын каплый аламы?

– Юк, бу мөмкин эш түгел. Бер генә фильм да, зур прокатка чыкмыйча, үзен үзе аклый алмаячак. Болай ул 3–4 миллион сум акча эшли ала. Федераль прокатка чыкканда (ә бу – уртача мең кинозалга юл ачылу дигән сүз), табыш алып була. Иң начар прокатта да 20–25 миллион сум акча эшләп була. Әмма татар киносы бу этапта табыш китерер дип көтәргә кирәкми. Аңа ныклап аякка басарга, федераль дәрәҗәгә чыгарга ярдәм итәргә кирәк. Ул Татарстанның имиджы өчен мөһим. Хәер, моны Президент та яхшы аңлый. Ул бит киногa авыр вакытта да финанс ярдәме күрсәтә.

:: Шул ук вакытта Россиягә үз продукцияңне куллану бурычы куела бит. Әйтик, Дәүләт Думасы вице-спикеры Анна Кузнецова тиз арада балалар өчен мультфильмнар һәм уенчыклар җитештерү бурычын куйды. Аның әйтүенчә, бу продукция 2024 елда 34 процентны тәшкил итәргә тиеш. Ә безнең татарча мультфильмнар балаларны кызыксындырырлыкмы соң?

– Мультфильмнар ул – глобаль мәсьәлә. 5–10 яшендә баланың дөньяны күзаллавы формалаша. Ягъни ул – нинди илнең гражданины? Мәсәлән, мин советлар илендә үзебезнең мультфильмнарны карап үстем, шулар тәэсирендә формалаштым. Ә хәзер кызыма карыйм да аның безнең ил турында бернәрсә дә белмәвен аңлыйм. Ул Америка мультфильмнарын карый, уеннары да шул мультфильм геройлары тирәсендә корыла. Хәзер яңа мода барлыкка килде. Алар Корея кейпопларына мөкиббән. Әлбәттә, балаларга үз мультфильмнарыбыз кирәк. Үсеп баручы буын турында уйлыйбыз икән инде, болай да бара, аннары эшләрбез әле дигән мөнәсәбәт ярамый. Балалар тәрбиясендә кинематограф – иң үтемле чара. Һәм ул дәүләт күзәтүендә булырга тиеш. Моңа кадәр безнең кино заллары Америка фильмнары белән тулы иде. Янәсе, халык аңа йөргән, табыш шуннан кергән. Табыш кергәндер, ә бит халык аңын башка ил эшкәрткән булып чыга. Кызганыч, бу күренеш бер кинематографка гына кагылмый.

> Бездә «регинальщик» дигән сүгенүгә тиң бер сүз бар. Мин «регинальщик» түгел, мин – үз өендә яшәүче татар. Әллә Мәскәүдә яшәсәң генә режиссер булырга хакың бармы? Талантлар үз өйләрендә яшәп эшләргә тиеш. Карашларны үзгәртергә вакыт җиткәндер инде.

Кинохрониканы җимереп, нәрсәгә ирештек? Документаль жанр бөтенләй туктап калды. 2002 елга кадәр республика төзелешләре, кешеләр, тормыш турында күзаллап була, ә аннан соң ни кала? Ачылышына Президент барган объектлар турында кадрлар гына тарихта кала...

:: Фильм төшерергә ниятләгән яшь режиссерга нинди киңәш бирер идегез?

– Режиссер булырга җыенган яшьләргә, үз тормыш тәҗрибәмнән чыгып, тагын бер кат яхшылап уйларга киңәш итәр идем. Башта ул шундый матур дөнья булып күренә. Ә кинематографист булырга җыенасың икән, син үз өлкәңдә иң яхшысы булырга, шуның өчен, ничек кенә аянычлы тоелмасын, Мәскәүгә китәргә кирәк. Мәскәү белән эшләмәсәң, сыйфатлы, халык таный торган режиссер булмаячаксың. Төбәктә калсаң, үзеңне шәп режиссер дип санасаң да, сине танымаячаклар, белмәячәкләр. Илле яшемдә миңа республикам өчен шактый эшләдем кебек тоелды. 300 картина төшерелгән, шул исәптән 4 тулы метражлы фильм бит инде. Әмма миңа кайчакта, үзегезнең нинди эшкә алынуыгызны белдегез бит инде, дигән мөнәсәбәт тоярга туры килә. Менә шуңа артык хыялланырга кирәкми. Шулай да, яраткан эш белән шөгыльләнү ул – бәхет. Акча дип тормышыңны яратмаган эш белән бәйләү – зур бәхетсезлек. Нишлисең, яраткан эш белән тормышны алып барып булмагач, коммерцияле проектларга алынырга туры килә. Ярыйсы гына килеп чыга. Әмма аңа заказ бирүче, аның хатыны, әбисе, бабасы, тагын әллә кемнәр кул тыга, төзәтергә туры килә. Син, әлбәттә, төзәтәсең, тик бер мәлдә, беркемгә дә кирәкмәгән бу «фарш»ка ник алындым соң, дип, башыңа тотынасың. Ул бит тарихта калмаячак.

Ә кино өлкәсен бу рәвештә калдырырга, проблемаларга күз йомарга ярамый. Әйтик, кино төшерү өчен грант конкурсы бар. Аның гомуми суммасы – 8 миллион сум. Егерме ел буена әлеге сумманың үзгәргәне юк. Сез әйткән яшь режиссер шушы конкурста 500 мең сум ота ала. Шуның 100 меңен ул бурычларын түләргә тотачак. Аннары командасына хезмәт хакы түләячәк. Аннары төшерергә кирәк. Әле бу – ярты юл гына. Төшергәннән соңгы эшкә аның бер тиене дә калмаячак һәм ул бурыч капкынында калачак. Мескен рәтле әйбер дә төшерә алмый, табыш турында сүз дә юк инде. Менә шундый баскычларны үтәргә туры киләчәк.

Мин бу турыда ничә ел сөйлим, әллә ишетмиләр, әллә ишетәселәре килми. Һич югы кино буенча эш төркеме булса да төзергә кирәк. Дәүләт Советы утырышында кино мәсьәләләренә 10 минут кына вакыт бирелсә дә, начар булмас иде.

:: Берлек бу вазгыятьтә яшьләргә ярдәм итә аламы?

– Мин берлеккә килгәндә, ул ветераннар клубы иде. Консерватив карашлы 33 кеше үз арасына яшьләрне кертергә бик теләмәде. Берлеккә килү белән, 15 кешене әгъза итеп алдык. Хәзер бездә яшьләр күбрәк. Актерлар, башка һөнәр кешеләре дә кушылды. Арабызда телевизион документалистларны да күрәсебез килә. Яшьләр өметле. Мин Байбулат Батулланың да үзебезнең арабызда булуын телим. Мәскәүдә эшләсә дә, ул бит – үзебезнең егет. Берлек мәсьәләсенә кайтсак, без яшьләргә «профессиональ кинематографист» дигән билге бирәбез. Ләкин алар сафына, әйтик, туй барышын төшергән кешеләрне дә алып булмый. Без фундаменталь

белеме булган талантларга ярдәм итәргә тиеш. Кызганыч, нәкъ менә аларга чаялык җитми. Берлек 5–6 кешене еллык стипендия түләп укыта. Ә инде кайтамы алар укып бетергәч Казанга, юкмы, анысы – икенче мәсьәлә.

> Мин үзем дә – башта Мәскәүдә 15 ел эшләгәннән соң Казанга кайтып төпләнгән кеше. Яшерен-батырын түгел, Мәскәү миңа, бәлкем, әле якынрактыр да. Чөнки Казан – ябык һәм монда икейөзлелек күп. Уйлап чыгарылган ясалма кагыйдәләр күп, үзеңне контрольдә тотарга кирәк, монда ирек азрак. Син, берәр эшкә алынганда, бихисап фикерләрне исәпкә алырга тиешсең. Мәскәүдә алай түгел. Анда мондый кагыйдәләр юк. Казахстанда да хәзер иркенлек. Алар теләсә кайсы темага төшерә ала. Ә монда фильмдагы вак мәсьәләдән фил ясый алалар.

:: Сезнең Тукай турында фильм хәзер нинди хәлдә?

– Әлегә бернинди стадиядә дә түгел. Күп укыйм, эзләнәм. Башка сценарийларны да укыйм. Быел Россия кинофестивальләрендә берничә премия алгач, Россия сценаристлары игътибар итте. Бәлки, Россия фильмына алынырга кирәктер… Татарчага ярдәм булмагач… Әйтегез әле, татарча кино кемгә кирәк? Мондагы 500 зыялыгамы? Аларның да бит кинозалга күп дигәндә иллесе киләчәк. Кем өчен эшләргә тиеш мин? Шушы урында авыл кешесенә рәхмәт әйтәсем килә. Республика прокатына чыккач, аларның нинди рәхмәтле булуына тагын бер кат инандым.

:: Ә уртак проектлар бу җәһәттән ярдәм итәме?

– Бу – бик яхшы идея. Чын мәгънәсендә продюсерлар һәм чын мәгънәсендә көчле команда булса. Акча каеру өчен генә ниятләнгән проект булса, аңа алынырга кирәкми. Ул «Ничек фильм төшерергә ярамый» дигән пособиегә әверелергә мөмкин.

Тагын бер проблема бар. Бездә кино тәнкыйтьчеләре юк. Әгәр алар булса, миңа интервью бирергә дә кирәкмәс иде. Мәскәүдә – иҗат иркенлеге, дидем. Чөнки анда күзгә карап тәнкыйтьләү һәм аны кабул итү бар. Анда эш тәртибе шулай корылган. Ә бездә кимчелеген күрсәтеп кара, гомерлек дошманга әвереләсең.

:: Үкенәсезме?

– Хатын: «Синнән яхшы табиб чыгар иде», – дип кабатларга ярата. Бәлкем, шулайдыр. Ә мин профессияләр рәтендә булмаган һөнәрне сайладым. Әмма үкенмим. Миннән соң эшем кала.

:: Хезмәт хакы аласызмы?

– Юк.

:: Язучылар берлегендә, мәсәлән, рәискә хезмәт хакы каралган.

– Бу хакта Дәүләт Советында сөйләшү булды. Бу эш Финанс министрлыгына чаклы барып җитте, әмма әлегә хәл ителмәде. Миңа калса, ул хәл ителер. Бу зарлану түгел, чөнки мин һәрвакыт аучы халәтендә яшим һәм тормышны алып барырлык рәтем бар. Миңа – 50 яшь һәм үземне өлгергәнлек чорына кердем дип саныйм. Минем – үз карашым, үз киском. Ул – минем буын, безнең вакыт, безнең карашлар турында. Әле тагын бик күп җитди картиналар төшерәсе бар. Ә кино проблемалары турында сөйләргә, оялмаска кирәк. Тик ул сөйләшүләр күз буяу өчен генә булмасын иде. Бер-беребезне тыңларга, тәнкыйтьне объектив бәяләргә өйрәнсәк иде.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ФӘНИС ЯРУЛЛИН

СӘЕР КУНАК

(ХИКӘЯ)

< Ахыры. Башы 25 ноябрь санында

– Инде аны хәзер туктатырмын димә, – ди Хәерниса түти, – таңга кадәр сөйләячәк.

– Сөйләсен әйдә, – ди кунак.

– Фронттан кайтып төшкәч, өч төн буе тоташ сөйләде ул, – ди Хәерниса түти. – Алай да сугыштагы өч көнен генә сөйләгән булып чыкты. Хәзер инде сугыш беткәнгә дә илле елга якынлаша, тик һаман сөйләнеп бетми әле.

– Бетми шул, – диде Мөдәррис абзый, карчыгына хәтере калып. – Беләсең килсә, сугышның бер көне бер елга тора аның.

Карт белән карчык үзара җиңелчә генә әйткәләшеп алалар. Картын яратып кына үрти Хәерниса. Дөресен әйткәндә, Мөдәррисенең әллә нинди түрәләрне авызына карата алуы белән горурлана әле ул.

Инде Мөдәррис абзый сәер кунагына ярыйсы ук күнеккән, Әхмәт Дилүсович үзе дә ачылып сөйләшә башлаган иде, беркөнне председательнең шоферы аңа нниндидер хат китереп бирде. Әхмәт Дилүсович бу хатны укыгач, әр-яңадан элеккечә йомыкланды, ашарын ашамас булды. Мөдәррис абзыйның: «Әллә берәр күңелсез хәбәр释бармы?» – диюенә җавап кайтармады. Ә бераздан капыл гына юлга җыена башлады. Сумкасына сөлге ише нәрсәләрен салгач, нидер исенә төшкәндәй бераз еракка карап торды да: «Киткәнче тагын бер мәртәбә урманнарны карап килим әле булмаса», – дип мылтыгын чехолыннан салдырып, җилкәсенә элде.

Ул урманга кереп китеп, озак та тормады, мылтык шартлаган тавыш ишетелде. Мөдәррис абзыйның сисканүдән кулындагы баллы тустаганы төшеп китте. Ерак та түгел өере белән каргалар очканы күренә башлады. Алар әллә нинди тавышлар чыгарып каркылдаштылар, кемгәдер ачуланалар иде бугай. Мөдәррис абзыйның күңеленә шомлы уй йөгерде: «Әллә инде… Әллә… Алла сакласын».

Билендәге озын алъяпкычын барган уңайга гына чишеп, агач ботагына гына элде дә мылтык тавышы ишетелгән якка йөгерде ул. Әхмәт Дилүсович белән алар маңгайга маңгай бәрелешә яздылар.

– Син… син исән, – диде Мөдәррис абзый, кунагының теп-тере килеш агачлар арасыннан килеп чыкканына сөенеп. Ул үзенең кабалануы аркасында Әхмәт Дилүсовичның кулындагы әйбергә дә әһәмият бирмәгән иде.

– Менә! – диде Әхмәт Дилүсович. – Әллә каян гына агачлар арасыннан килеп чыкты. Чакмага басканымны сизми дә калдым.

Ул Мөдәррис абзыйның аяк астына җансыз төлке гәүдәсен ташлады.

– Ялкын, – диде Мөдәррис абзый, төлкене танып. – Безнең Ялкын!

Мөдәррис абзыйның кинәт тез буыннары калтырап китте. Ул чүгәләде дә җирдә сузылып яткан төлкенең йомшак йоннарын сыйпарга тотынды. Әхмәт Дилүсович исә һаман акланырга теләгәндәй:

– Мылтык астына үзе килеп керде. Аякка уралыпмы урала. Төлке атарга дип ниятләнеп чыкмаган идем, – дип сөйләнде.

– Мылтыкны кулга алдыңмы, ата инде ул, – диде Мөдәррис абзый, чүгәләгән җиреннән торып. – Мылтык астына үзе килеп керде, имеш. Ә беләсеңме ни өчен ул мылтык астына үзе килеп кергән?

Әхмәт Дилүсович «ни өчен соң?» дигәндәй Мөдәррис абзыйга текәлде.

– Аның әнә анда оясы бар, ә оясында – өч баласы. Балалары янына синең якынлашып килүеңне күргән дә, сине туктатып калу өчен, атылып каршыңа чыккан.

– А-а-лай! – диде Әхмәт Дилүсович, бераз сузып. – Балаларын коткарып калу өчен диген, ә?

Карт умартачының «балаларын коткару өчен» дигән сүзләре Әхмәт Дилүсович күңелендә ниндидер уйлар кузгатты бугай, ул озак кына җирдә сузылып яткан үле төлке гәүдәсенә карап торды. Аннары Мөдәррис абзыйга күтәрелеп:

– Менә сез, Мөдәррис абзый, бик күзәтүчән кешегә охшыйсыз, әйтегез әле: аналарына яки аталарына үлем куркынычы янаганда берәр җәнлекнең баласы аны коткарып калу өчен үзе мылтык астына килеп кергәне бар микән?

– Андый нәрсәне күрергә туры килмәде, – диде Мөдәррис абзый.

– Димәк, кешеләрдәге мондый сыйфатлар кыргый җәнлекләрдән үк килә икән. Димәк, бу – инстинкт, – дип үзенә нәтиҗә ясады Әхмәт Дилүсович.

Тагын байтак вакыт сүзсез утырдылар. Соңыннан Әхмәт Дилүсович төлкегә таба ымлап:

– Инде моны нишләтәбез? – диде.

– Тунарга кирәк, – диде Мөдәррис абзый. – Рас җан кыйгансың икән, берәр файдасы булсын.

– Юк, юк, – диде Әхмәт Дилүсович, – мин андый эшнең рәтен белмим. Тунаган очракта да аның тиресе белән мин нишлим?

– Хатыныңа яки кызыңа якага булыр.

Кунак ниндидер сәер караш белән Мөдәррис абзыйга карап куйды. Аның күңелендә кайнаган уйларын карт умартачыга түгел саласы килә, әмма горурлыгы җибәрми иде бугай.

– Әйдә булмаса, моны җиргә күмик, – диде Мөдәррис абзый. – Балаларының күзенә чалынмасын.

– Күмәргә?

– Әйе. Чөнки тиресен тунарга минем дә кулым бармый.

Алар умарталыктан көрәк алып килеп, төлкене күмеп куйдылар. Бераздан Мөдәррис абзый болай дип сүз башлады.

– Бу төлкене мин өч ел беләм инде. Бервакыт шулай кыш көне подвалдагы умарталарның хәлләрен белергә дип бирегә килгән идем. Эшләремне бетергәч, келәткә дә сугыласы иттем. Келәткә якынайгач, эчтә ниндидер тавыш ишетеп, сагаеп тәрәзәгә килдем. Тәрәзә аша карасам, ни күзләрем белән күрим: бер төлке почмакта балавыз ялап маташа. Әйе, келәттә минем балавызлар саклана. Шунда кергән бу. Келәт тәрәзәсенең бер бүлкәсе ватылгач, полиэтилен кадаклап куйган идем, шуның бер почмагын ерткан да кергән. Тома балавызның исе бик көчле бит аның…

– Тома балавыз?

– Әйе, китапча итеп әйтсәк, прополис була инде.

– Ә, ишеткән бар андый нәрсәне.

– Күрәсең, бу көлтә койрыкның эчтә туктаусыз борчучы берәр авыруы булгандыр. Ә җәнлекләр алар – үзләренә үзләре доктор. Тома балавызны ашарга килгән. Мин аның белән берничә мәртәбә күзгә-күз дә очраштым. Тора-бара ул миннән бөтенләй курыкмый башлады. Күзгә күренеп тазарып, матураеп китте. Җәйгә чыккач, бермәлне югалып торган иде, балалап яткан икән. Көннәрдән бер көнне бу, өч баласын ияртеп, минем келәт турысыннан ике әйләнде. Янәсе, күр, менә минем нинди балаларым бар.

Әхмәт Дилүсович көрсенеп куйды.

– Әйе, сезнең өчен кадерле җан иясе булган бу. Кем уйлаган аны мылтык астына керер дип.

– Күрәсең, вакыты җиткәндер, – диде Мөдәррис абзый. – Аның каравы ул үзенең балаларыннан тыш тагын бер гомерне коткарып калды.

Әхмәт Дилүсович умартачының сизгер күңеленә исе китеп сүзсез калды. Аннары ул капыл гына урыныннан торды да:

– Ярый, – диде, – юл кешесенең юлда булуы яхшы. Сезгә барысы өчен дә рәхмәт.

Сәер кунак күңел төенен чишми китеп барды. Киткән вакытта ул үз-үзенә сөйләнгәндәй: «Димәк, җәнлекләрнең балалары да ата-анасын коткару өчен үлемгә ташланмый», – диде. Бу сүзләрнең эчкәреге мәгънәсендә Мөдәррис абзый, әлбәттә, төшенмәде һәм бервакытта да төшенмәгән булыр иде. Ләкин беркөнне теге төлке оясы яныннан үткәндә, аның күзенә йомарланып ташланган бер кәгазь кисәге чалынды. Мөдәррис абзый кәгазьне алды. Ул ярты ягы каядыр юкка чыккан хат кисәге иде.

«Әти, – дип язылган иде анда, – сине агартыр өчен, мин карала алмыйм, бигайбә. Кем әйтмешли, синең инде җырың җырланган, ә минем яшисем бар әле. Бүтән миңа…»

Хат шушы урында өзелгән иде. Мөдәррис абзый көрсенеп куйды. «Әй балалар, балалар! Ата-ана өчен берегез дә үләргә тормый шул. Бәлки әле күп очракта үлү түгел, таяныр өчен иңгезне кую да җитәдер. Әмма түбән тәгәрәгән кешегә иңеңне куйсам, югарыдагылар үземне яратмас дигән курку күңелегездәге шәфкатьне үтерә. Шул куркуны эчтән куалап чыгармый торып, игелек эшләү авыр, бик авыр».

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясенең
30 ноябрь, 2022 ел,
№ 6/32 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Азнакай шәһәре территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәре

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Азнакай шәһәре территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Азнакай шәһәре территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында игълан итә.

Документлар 2 декабрьдән 16 декабрьгә кадәр 9.00–18.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7 б й. (элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33).

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Муниципаль берәмлекләрнең территориаль сайлау комиссияләрен, сайлау комиссияләрен, округ һәм участок сайлау комиссияләрен формалаштыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 17 февраль, 2010 ел, №192/1337-5 Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

5–15 декабрь көннәрендә ташланмалы бәяләр

П2435
җомга саны
гадәти бәясе ~~512 сум 70 тиен~~
444 сум 54 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
гадәти бәясе ~~1143 сум 96 тиен~~
980 сум 10 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+ реклама



Әз-мәз мәзәк

– Безнең Җир шарының зурлыгын күз алдына китер син. Ә кояш? Кояш бит тагын да зуррак! Ә бит Кояш та, Җир дә, бөтен галәм масштабында карасаң, бары тик тузан бөртеге генә!
– Аңладым, өч мантый күбрәк булыр, икене генә ашыйм.

* * *

Шундый заман килде: антидепрессантларны хәзер су кранына ук кушарга була.

* * *

Йолдызнамәдә иң начар йолдызлык – синең элек йөргән егетеңнең йолдызлыгы.

* * *

Күп еллар үземне акча тота белмәвем өчен битәрләдем. Баксаң, бар гаеп минем хезмәт хакымның бик кечкенә булуында икән.

* * *

Ике балалары белән туганнарыбыз кунакка килгән иде, песиебез шундук үлгән булып кыланды.

* * *

Россия футбол җыелмасы икегә бүленеп, бер-берсе белән уйнаса, бәлки, берәрсе отар иде?

Яшь бара бит, егетләр!

- Үскәч кем булырга теләвеңне, иң мөһиме, 30 яшькә кадәр аңларга.
- Мин шундый яшьтә ки, әз генә буш вакытым булган саен ятып торасым килә.
- Минем әби минем бабайга кияүгә чыккан, минем әни – минем әтигә, ә мине бер белмәгән кешегә кияүгә бирмәкчеләр!
- Минем белән булганда курыкма. Мин, беләсең килсә, спортзалга йөрим. Хулиганнар очраса, кулларны алга сузып, 7 тапкыр утырып, 7 тапкыр тора алам!
- Олы яшьтә булуыңны шуннан аңлап була: калган акчаңа башта кайсы табибка барырга икән дип баш ватасың.
- Безнең яшь чакта экокожа дигән нәрсә дермантин дип атала иде.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: ишан, Җәлил, Садә, яңалиф, па, Франция, ир, Ило, ярд, Ралиф, Миркәй, Шо, анонс, абзар, әз, гафу, бәйрәм, ия, Ра, ярты, зина, Рамил, Луаз, илә, гайре, инеш, кран, шалт.

Вертикаль: Ринат, казылык, шоңкар, Илназ, ага, ли, наз, арзан, си, офшор, бия, Гафифә, он, Ярамир, им, Сааб, Илеш, җәллад, Фәгыйлә, яр, уй, ил, цирк, ант, Ирдәүкәләр, Лилия, Мамадыш.

Беләсең килсә...

1 Чиабатта нәрсә ул?
а) итальян чабатасы;
б) итальян ипие;
в) итальян биюе.

2 Аш-суда кулланыла торган тозның химик формуласы нинди?
а) NaOH;
б) $NaHCO_3$;
в) NaCl.

3 Танылган шагыйрь, әдәбият белгече Равил Рахманиның чын фамилиясе нинди?
а) Соколов;
б) Синицин;
в) Кукушкин.

4 АКШ ничә штаттан тора?
а) 45;
б) 50;
в) 51.

Җаваплар: 1. б); 2. в); 3. в); 4. б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 378

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булерак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+